ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ИНТЕРАКТИВ ЭШ ФОРМАЛАРЫ һәм ТЕКСТЛАР

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ИНТЕРАКТИВ ЭШ ФОРМАЛАРЫ ҺӘМ ТЕКСТЛАР

КАЗАН
2024

ББК 74.268
И73

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 августында 730 номерлы карары белән расланган «Татар халкының милли тәңгәллеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә басыла

Төзүчесе:
Шәмсетдинова Р.Р., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент

Интерактив эш формалары һәм текстлар / төз. Р.Р. Шәмсетдинова. — Казан: ТРМҮИ, 2024. — 53 б.

Методик ярдәмлек белем бирү оешмаларында эшләүче туган тел (татар теле) һәм әдәбият укытучыларына тәкъдим ителә. Федераль дәүләт стандартлары белем бирү процессында актив һәм интерактив эш формаларына нигезләнүне шарт итеп куя. Әлеге хезмәттә интерактив эш ысулларыннан текст белән эшләүнең төрле формалары карала.

© ТРМҮИ, 2024

Актив һәм интерактив эш формалары — стандарт таләпләрен тормышка ашыруның нигезе

Федераль белем бирү стандартында укучыларның предмет нәтиҗәләргә эшчәнлекле формада ирешүләре, белемнәрен, конкрет осталыкларын урынлы куллана белүләренең әһәмияте ассызыклана. Шуңа бәйле рәвештә укытучылар алдына яңа универсаль уку гамәлләрен формалаштыру һәм белем алуга мотивлаштыру максаты куелды. Стандартның нигезе — укытуга системалы-эшчәнлекле якын килү. Бу исә танып-белү процессында укытучының укучы белән хезмәттәшлегенә мөнәсәбәтне үзгәртүне сорый. Белем бирүнең максаты булып, билгеле бер күләмдәге белемнәрне укучыга тапшыру түгел, бәлки укучы шәхесенең үсеше, аның сәләтен, кызыксынуын үстерү өчен шартлар тудыру тора. Белем бирү нәтиҗәләрен бәяләүдәге яңа юнәлешләрне билгеләү (шәхси, метапредмет, предмет) контроль-бәяләү эшчәнлеген оештыру мәсьәләсе килеп баса (РФ Мәгариф министрлыгының 05.2021 ел 287 нче номерлы боерыгы, 9нчы пункт). Димәк, педагогларга педагогик системаның элементларын гына алыштыру түгел, бәлки үз эшчәнлекләренең бөтен системасын үзгәртү ихтыяҗы туа, дәресне укыту эшчәнлегенең логикасына таянып, ситуация — проблема — мәсьәлә — нәтиҗә эзлеклелегендә проектлаштырырга өйрәнергә кирәклеге көн кадагына баса, бу исә эшчәнлеккә ирешүнең яңа юлларын билгели:

- дәресләрдә тормыш ситуацияләрен модельләштерү һәм анализ;
- актив һәм интерактив методикаларга нигезләнү;
- проект эшчәнлегендә катнашу, тикшеренү эшчәнлегенең алымнарын үзләштерү;
- укучыларны куелган мәсьәләне хәл итүдә мөстәкыйльлеккә урын калдыра торган уен, дискуссия, рефлексия, проект кебек эшчәнлек формаларына тартуны таләп итә.

Димәк, алгы планга белем бирүнең актив формалары чыга. Актив ысуллар гамәли юнәлешлелекләре, уенга корылган булулары, ижади характерда булулары, эшне оештыру формалары белән аерылып торалар. Интерактив укыту — актив белем бирүнең аерым методы. Бу метод педагогка укучыларны дәрескә кызыксыну уятырга, аларның уку процессында активлыгын тәэмин итәргә, уңай нәтиҗәләргә ирешергә һәм коллектив эшчәнлеккә җәлеп итәргә ярдәм итә. Интерактив белем бирүнең нигезен уку процесын укытучы — укучы, укытучы — сыйныф, укучы — сыйныф, укучы — укучы, төркем-төркемнәрнең үзара актив хезмәттәшлеге шартларында алып барылуы тәшкил

итә. Укучылар үзара хезмәттәшлек итү барышында аралашырга, тәнкыйди фикерләргә, нигезле карарлар кабул итәргә өйрәнәләр .

Интерактив ысуллар белем бирү системасында бөтенләй яңа төшенчә булып тормый. Россиядә актив һәм интерактив ысуллар әле 20 нче гасырның 20нче елларында ук гамәлдә була (проект, лаборатор, бригада ысуллары, хезмәт практикасы, экскурсиялә һ.б.). Алга таба бу ысулны тирәнәйтү, киңәйтү Сухомлинский, Шаталова, Амоношвили, Лысенкова, Махмутов, Яхин, Рәхимов һ.б. талантлы педагогларыбыз тарафыннан башкарыла.

Интерактив белем бирү актив социаль-психологик белем бирүнең заманча юнәлешен тәшкил итә. «Интеракция»төшенчәсе (инглиз теленнән. «*Interaction»* — тәэсир итешү, аралашу) иң беренче булып социология һәм социаль психологиядә кулланылы башлый. Для теории Символик интеракционизм теориясе өчен (нигез салучысы — америка фәлсәфәчесе Дж. Мид) шәхеснең тормыш эшчәнлеген, үсешен, кеше тарафыннан үзенең “Мин” ен башка кешеләр белән аралашу, бәйләнешкә керү ситуациясендә барлыкка китерүен берләштереп карау характерлы. Психологиядә интеракция — ул нәрсә белән дә булса (мисал өчен компютер, китап) якм кем белән дә булса (кеше белән) бәйләнешкә керү, хезмәттәшлек итү. Инглиз телендә «интерактив» төшенчәсе *inter»* — үзара, «act» — эшчәнлек итүне белдерә.Димәк, «интерактив ысуллар» дигәндә, без укучыларга үзара хезмәттәшлек итергә мөмкинлек бирә торган ысулны күаллыйбыз.

Бер үк вакытта “интерактивлы”, “интерактив белем бирү”, “интерактив ысуллар һәм белем бирү ысуллары” кебек терминнар мәгариф системасында аралашу, кооперация, хезмәттәшлек итү процессларын чагылдырган хезмәтләрдә (Аветова, Бадмаев, Каратаева, Кларин, Руднева, Шамсутдинова, Замалетдинова) актив кулланылышта.

Интерактив ысулның төп бурычлары:

- белем алу мотивларын, укучыларның инициативасын һәм мәнфәгатьләрен үстерү;
- белем алу күнекмәләрен формалаштыру;
- коммуникатив компетентлыкны үстерү;
- иҗади эзләнү атмосферасы өчен шартлар тудыру;
- укучы һәм укытучы, укучы һәм коллектив арасында уңай эшлекле бәйләнеш булдыру;
- укучыларга белем алу һәм фәнни бурычларны хәл итү юлларын мөстәкыйль эзләү мөмкинлеген бирү;

- укучылар арасында үзара уңай эшлекле бәйләнеш урнаштыру, коллективта эшләү күнекмәләрен булдыру, башкаларның фикеренә карата хөрмәт һәм түземлелек тәрбияләү;

- белем бирү процессында башка катнашучыларның сүз ирегенә һәм абруен хөрмәт итүгә хокук саклау;

- кирәкле тормыш һәм һөнәри күнекмәләрне формалаштыру һәм үстерү.

Интерактив белем бирү методы төркемле һәм индивидуаль эш формаларын үз эченә ала. Төркемнәрдә эшләү үзе 3 төрле эш төрен күз алдында тота:

1) дискуссияле эш төрләре, мәсәлән: ми һөҗүме, мастер-класслар, проект эшчәнлеге, презентация, бәхәсләшү, кейслар, интерктив вебинарлар, тавыш бирү, сораштыру, “Микрофон” (куелган проблема буенча укучыларның чыгышлары), “Броун хәрәкәте”, ротацион өчлекләр (һәр бирем саен составлары үзгәрә торган өч кешедән торган төркемле эш).

2) уеннар: дидактик уеннар, эшлекле уеннар, рольле-сюжетлы уеннар;

3) тренинг-методлар: социаль-психологик тренинглар, эшлекле аралашу тренинглары, психотехник уеннар.

Хәзерге чорда белем бирүнең төп максаты булып аның шәхес, җәмгыять һәм дәүләтнең актуаль таләпләренә җавап биреүе, тормышка социаль җайлашуга, хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрүгә, белем алуга, камилләшүгә сәләтле шәхес тәрбияләүгә юнәлдерелгән булуы тора. ФДББС та чагылыш тапкан социаль таләп — ул укырга өйрәтү таләбе. Интерактив ысуллар тулысынча әлеге таләпләрне тормышка ашыруда нигез булып торалар. Укучылар үзара хезмәттәшлек итү барышында аралашырга, тәнкыйди фикерләргә, нигезле карарлар кабул итәргә өйрәнәләр. Алга таба педагогик практикада уңышлы кулланыла торган кайбер интерактив эш формаларына тукталып китик.

Интерактив эш төрләреннән үрнәкләр

Антиципация (лат. anticipation) — алдан эшләү, алдан сизү, алдан күрү кебек мәгънәләрне белдерә. Теләсә кайсы текстны укуның төп “продукты” буларак кабул итү һәм аңлау. Шуңа күрә текстны укый башлаганчыга кадәрге булган беренче этапта уку осталыгының антиципация дип аталган формасын үстерү бик мөһим. Бу этапта авторның фамилиясе, текстның атамасы, иллюстрация буенча текстның эчтәлеген күзаллау, фаразлый алу кебек

осталыкны үстерү өстендә эш алып бару юнәлеше нигезләнә. Мисал өчен, Габдулла Тукайның “Каз” хикәясе буенча интерактив эш оештыру.

- Хәрефләрне күчереп, үзегез укыячак хикәянең авторын ачыклагыз (АКУТЙ — ТУКАЙ)
- Сезгә бу автор танышмы? Аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар?
- Бу хикәя нәрсә һәм нинди вакыйга турында булыр икән? (Укучылар исеменнән чыгып фаразларны җиңел генә ясый алаячак.
- Соңгы җөмләне кабат укыгыз. Анда әйтелгән фикер белән килешәсезме? Ничек уйлыйсыз: ни өчен?
- Беренче җөмләне укыгыз: ни өчен шулай дип уйлады?
- Икенче җөмләне укыгыз: ни өчен ташлады?

Ми штурмы алымы укучыларны активлаштыра, куелган мәсьәләне чишүгә ярдәм итә, стандарт булмаган фикерләү формалаштыра. Бу ысул дөрес яки дөрес түгел җавап рамкалары куймый. Укучылар авырлыктан чыгуга, мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерелгән теләсә нинди фикер әйтә алалар .

- Сез татар халык әкиятләренең нинди төрләрен беләсез? (Көнкүреш, тылсымлы, хайваннар турында)
- Һәр төр әкияткә хас булган билгеләрен әйтегез.
- Алдан күрүләр агачы алымы

образлы фикерләүне үстерергә ярдәм итә, аргументларны һәм фактларны чагыштырырга, фантазияне үстерергә, киләчәкне күрә белергә өйрәтә. Әлеге алымны америка галиме ДЖ. Беллансон әдәби әсәр тексты белән эшне оештыру максатыннан чыгып эшли. Дәрес темасы билгеләнгәннән соң биремнәр китерелә.

- Агачның яфракларына үзегезнең бу дәрестән нәрсәләр көтүегезне языгыз.
- Дәрес азагында, рефлексия этабында әйтелгән фикерләр анализлана һәм агачта бары тик расланган фикерләрне чагылдырган кәгазьләр генә кала.

Логик чылбыр алымы күләмле мәгълүматны аңларга һәм истә калдырырга, ниндидер вакыйгаларның, күренешләрнең закончалыкларын билгеләргә ярдәм итә. Алым тәнкыйди фикерләүне, хәтерне үстерә, логик фикерләү сәләтен арттыра. Алымның нигезен фактлар, җөмләләр, сүзләр, даталар, кагыйдәләр, цитаталарның логик яки хронологик тәртипкә салынган чылбыры тәшкил итә. Чылбыр укытучы белән бергә дә төркемнәрдә дә, парларда да, мөстәкыйль дә төзелергә мөмкин. Мисал өчен, Габдулла Тукайның яки башка язучының биографиясен өйрәнгәндә.

Блум кубигы алымы тәнкыйди фикерләү технологиясенә карый. Алымннан файдалану өчен ян-якларына түбәндәге сүзләр язылган кәгазь куб кирәк була:

Ата (назови)
Ни өчен
Чагыштыр
Тәкъдим ит
Уйлап тап
Бүлеш

Укытучы кубикны ыргыта. Өске яктагы язу биремнең төре санала, шуның буенча сорау төзелә. Баштарак сорауны укытучы бирә, соңрак укучылар үзләре сорау куя башлыйлар.

Мисал өчен, “Өч кыз” әкиятен өйрәнгәндә бирелергә мөмкин булган сораулар

- Әкиятнең төп геройларын ата.
- Ни өчен тиен төпчек кызга изге теләкләр тели?
- Өч кызны чагыштыр.
- Кызларның ялгышларын төзәтү юлын тәкъдим ит.
- Тиен белән төпчек кызга исем уйлап әйт.
- Төпчек кыз синдә нинди хисләр уятты, шул турыдага фикерең белән бүлеш.

“Дөрес — дөрес түгел” алымы материалны, мәгълүматны гомумән аңлу-аңламауны, төгәл аңлауны тиз генә тикшереп алырга мөмкинлек бирә.

Мәсәлән, шул ук “Өч кыз әкияте”

Әни кеше тиен белән шәһәрдә яшәгән.

Өч кызның икесе кияүгә чыгып киткән.

Олы кыз тиен хәбәр китерүгә әнисе янына йөгергән.

Кызлар өчесе дә әниләренә ярдәм итәргә килгәннәр.

Әниләре тазарып аякка баскан.

Синквейн алымы текстны аңлауны тикшерүгә юнәлдерелгән ижади эш булып тора. Алым укучыларның парларда, төркемнәрдә эшләвен күз алдында тота. Синквейн — рифмалашмаган бишьюллык шигъри формада язылган кыска әдәби әсәр.

1 нче юл.Теманы ачыклаучы сүз, исем. *(Кызлар)*

2 нче юл. Синквейн темасына туры килә торган ике сыйфат. *(Игелекле, игелексез)*

3 нче юл. Синквейн темасына хас булган өч фигыль. *(Чистарта, бәйли, камыр баса)*

4 нче юл. Теманың эчтәлеген ачучы фраза, җөмлә. (*Тиен үз бәясен бирә)*

5 нче юл. Укучының темага карата үз фикерен бер сүз белән чагылдырган нәтиҗә. Резюме.*(Игелеклелек)*

«Кластер» алымы бәйләм, тәлгәш дигәнне аңлата. Бу алымның асылы — булган белемнәрне системага салу, яңалары белән тулыландыру. Кластер төзү укучыларга нинди дә булса тема буенча иркен фикер йөртергә ярдәм итә. Укучы кәгазь битенең, ватманның уртасына нигез төшенчәне язып куя, шуннан төрле якларга икенче сүз белән тоташтыра торган уклар сыза һәм шулай дәвам итә. Мисал өчен исем сүз төркеме буенча кластер төзергә мөмкин. Уртага исем сүзе языла һәм уклар исемгә хас булган үзенчәлекләрне, сыйфатларны ачыклый торган төшенчәләргә юнәлдереләләр. Шул рәвешле исем сүз төркеме төшенчәсенә хас булган мәгънәви кыр график чагылышта күрсәтелә.

Карусель алымы күбрәк сөйләм үстерү дәресләрендә кулланыла. Сыйныф берничә төркемгә бүленә, алар тәкъдим ителгән рәсемнәр арасыннан үзләренә ошаган бер рәсемне сайлап алалар һәм 1 минут эчендә рәсемне сурәтләрлек образлы сүзләр, сүзтезмәләр язалар. Аннан соң төркемнәр урыннарын алмаштыралар, рәсем астына үз сүзләрен өстиләр. Шулай төркемнән төркемгә күчеп язганнан соң, үз рәсемнәренә әйләнеп кайталар һәм картинаның эчтәлеген ачыклау өчен язылган сүзләрнең барысын да кулланып, рәсем буенча хикәя төзеп сөйлиләр.

Тәңгәллек эзләү алымы. Укучылар сүзләр һәм тәгъбирләрнең сурәтләүгә тәңгәллекләрен билгелиләр.

- Геройларны чагылдыручы сыйфатларны сайлагыз (һәр төркемгә конкрет герой бирелә).
- Әлеге сыйфатларны файдаланып, геройны сурәтләгез.

Укучыларга белем бирү тотрыклы мотивация урнаштырылу һәм танып-белү активлыгы булу-булмау белән турыдан-туры бәйле. Белем бирүдә чагылыш тапкан уңай нәтиҗәләр укучы шәхесен үстерүгә юнәлдерелгән интерактив эш алымнарының ни дәрәҗәдә уңышлы булуын чагылдыралар, укучының танып-белү эшчәнлеген үстерүгә хезмәт итәләр.

Туган (татар) теле һәм әдәбияты дәресләрендә, татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү барышында интерактив эш алымнарына нигезләнү

- эзләнү, төрле карарларны анализлауны таләп иткән максат һәм бурычларны кую;
- нәтиҗәгә ирешүгә этәрә торган эшчәнлек төрләрен сайлау;

- коммуникатив күнекмәләр һәм осталыкларны үстерү; башкарылган эш турында фикер йөртү;
- карарлар кабул иткәндә фикер йөртү, проблемаларга тәнкыйди якын килү;
- башкалар фикеренә хөрмәт белән карау, төркемнәрдә нәтиҗәле эшләү;
- үз фикереңне формалаштыра белү;
- белем алу процессына иҗади якын килү;
- мөстәкыйль, иҗади эләү осталыгын үстерү өчен шартлар тудыра.

Интерактив алымнарга нигезләнеп сөйләм эшчәнлегенең төрле формаларына өйрәтү аерым-аерым тел тамгаларына нигезләнеп тормышка ашырыла алмый, моның өчен бәйләнешле сөйләмне чагылдырган әсәрләр кирәк. Яңгырашлы яки язма чагылышлы текст коммуникациянең аерылгысыз өлешен тәшкил итә, ягъни тел өйрәнүнең мәҗбүри бер компоненты булып тора. Уку процессында текст күп төрле функцияләр башкара: текст чит сөйләмне аңлауны формалаштыруның нигезе ул (ишетү һәм уку барышында), укучыларга үзләренең сөйләмә әсәрләрен төзү өчен таяныч һәм стимул, шулай ук телгә караган яңа материал белән таныштыру чарасы һәм аны сөйләмдә куллану күнекмәләре булдыру өчен җирлек тә булып тора. ФДББС ында тел өйрәнүнең метапредмет нәтиҗәләренә барлык төр сөйләм эшчәнлегенә ия булу куелган. Аралашу сөйләм эшчәнлегенең бер формасы һәм ул нинди формада тормышка ашырылуына карамастан (телдәнме, язмамы, монологикмы, диалогикмы) интерактив эшчәнлек булып тора.

Текст интерактив эшчәнлекнең төп компоненты

Интерактив эшчәнлекнең төп компоненты булып текст хезмәт итә. Нәкъ менә текст автор белән укучы, тыңлаучы белән сөйләүчене бәйләүче звено хезмәтен башкара. Дәрестә текст белән эшләүнең бик күп төрле формалары бар. Шуларның кайберләренә тукталып китик

Укырга өйрәтү максатыннан текст.

“Кешеләр укымый башлауга, фикерләүдән туктыйлар” (Д.Дидро).

Күпчелек методистлар тарафыннан текстның әлеге функциясе төп функциясе буларак карала. Бу сөйләм эшчәнлегенең әлеге төренә ия булуның киң мөмкинлекләренә бәйле, укуның танып-белүдәге әһәмияте, аның көндәлек тормыштагы кулланылышы белән бәйле. Укуны белем бирүнең чарасы буларак та, максаты буларак та карарга кирәк. Уку текстлары еш кына уку техникасын

камилләштерү чарасы буларак үткән материалны нығыту, телнең грамматикасын һәм лексикасын үзләштерү чарасы буларак та карала. Бу аңлашыла да, ләкин тестны укырга өйрәтүнең төп бурычы мәгълүмат алуга юнәлдерелгән коммуникатив процесс буларак каралырга тиеш. Укырга өйрәтүнең башлангыч этабы уку текстының тел һәм эчтәлек ягына шактый чикләүләр кертә. Бу этапта текстны аңлауны кыенайта торган тел чаралары булмау төп шарт булып тора дигән фикер яши. Шуңа күрә укучыларга тәкъдим ителә торган беренчел текстлар, кагыйдә буларак, инде сөйләм теленә кертелгән, үзләштерелгән сүзләрдән торырга тиеш һәм алар эчтәлекле текст буларак кыйммәткә ия дә булмаска мөмкин, чөнки чикләнгән тел материалы белән текст төзү шактый кыен бурыч.

Танып-белү, мәгълүмати, эмоциональ көчкә ия булмаган текстлар табигый коммуникация берәмлеге була алмыйлар. Текстны төзүче, язучы үз алдына укучысына кызыклы мәгълүмат җиткерүне, аңа тәэсир итүне максат итеп куя. Текстның шушы үзенчәлекләре игътибар үзәгенә куелмаса, текст белән эшләүдә интерактив эшчәнлекне оештыруның нигезен җимерә, аны фәкать механик кабул итүгә китерә.

Уку өчен текстларга кергән таныш түгел лексика күләмен чикләү дә (башлангыч этапта) бәхәс уята. Бер яктан, чынлап та яңа сүзләр текстны кабул итүне катлауландыралар, ә икенче яктан, аларның мәгънәләрен эзләү ихтыяҗы дәрестә сөйләм эшчәнлеген активлаштыра. Сүзнең мәгънәсен эзләү табигый коммуникациянең һәм аны тормышка ашыру шартларын тудыру уку эшчәнлеген интерактив оештыруның мөһим элементы.

Шулай итеп, укырга өйрәтү — текстның уку процессындагы мөһим функцияләренең берсе. Укырга өйрәтүне сөйләм эшчәнлегенең бер төре буларак карау бурычы сайлап бирелә торган текстлар алдына да катгый таләпләр куя:

- текст укучыларның кызыксынуларын канәгатьләндерерлек булырга һәм тел белү мөмкинлекләрен исәпкә алырга тиеш
- текстлардан соң бирелгән биремнәр укучыны укуга мотивлаштырырлык, куелган мәсьәләләрне чишүгә кызыксынучанлыкларын үстерерлек, авторның ниятен табып булырлык, укытучы — укучы, укучы-укучы хезмәттәшлегенә нигез булырлык, текстның аерым өлешләренең логик эзлеклеген урнаштырып булырлык итеп төзелергә тиеш.

Тыңлап аңлауга (аудированиегә) өйрәтүдә текст. Сөйләм эшчәнлегенең бер төре буларак тыңлап аңлауның үзенчәлеге тыңлаучының бу эшчәнлекнең аерым параметрларын (әйтелмәләрнең күләме, аның лексик-грамматик

бирелеше, җөмләләр арасындагы паузалар һ.б.) көйли алмавы тора. Шулай ук сөйләүченең сөйләмендә күзәтелгән шәхси үзенчәлекләре, тыңларга комачаулык итә торган төрле факторлар да өстәмә авырлыклар тудыра. Аудиотекстларның күләме, кулланыла торган сүзләр саны, ягъни сан ягыннан характеристикалары шактый нык эшләнгән булып исәпләнә. Мисал өчен, башлангыч чорда текст яңгыравының озынлыгы бер минуттан артмаска тиешлеге эксперимен үткәрү юлы белән расланган, җөмләнең озынлыгы 5–6 сүздән артмаска тиеш [1].

Коммуникатив ысул аудиотекстларга яңа таләпләр куя. Табигый коммуникация шартларында текстның бурычы мәгълүмат җиткерү белән генә чикләнеп кала алмый, ул нәрсәгә дә булса инандыра, мөнәсәбәтен үзгәртә, нинди дә булса гамәлгә этәрә. Коммуникатив ният булу аутентик текстның мәгънәви тәмамланганлыгын, бөтенлеген, өлешләре арасында бәйләнеш, композицион бөтенлелек, жанр үзенчәлекләре сакланууны таләп итә. Телне аралашу чарасы буларак нәтиҗәле өйтү өчен уку текстында, шул исәптән тыңлап-аңлау текстларында әлеге параметрларның сакланууы мөһим.

Сөйләм эшчәнлеген уңышлы башкаруның мөһим шарты булып мотивация тора, аеруча-тыңлап аңлауга өйрәтүдә. Текстка конкрет таләпләр куелмаса, эчтәлеге кызыклы, җәлеп итәрлек булмаса, укучыларның (бигрәк тә кече яшьтәгеләрнең) игътибарын киметәчәк, ә аерым өлешләренә игътибар җитмәү текстны тулысынча кабул итүгә киртә булачак. Шуңа күрә укытучы алдында тыңлауны мотивлаштыру, активлаштыру, аңлап кабул итүне оештыру кебек җаваплы бурыч куела. Тыңлауның берничә интерактив төре билгеләнә: актив тыңлау — ачыктан-ачык чагылыш тапкан мәгълүматны кабул итү; интенсив — тыңлаганны фикерләү аша үткәрү, аңа аңлатма бирү. Соңгысы текст мәгълүмати һәм эмоциональ яктан бай булганда гына мөмкин.

Тыңлап-аңларга өйрәтүнең башлангыч чорында уку өчен текст, бер яктан, укучының үзе өчен кызыклы, кирәкле мәгълүматка ия булырга, икенче яктан, тормышның укучы өчен таныш өлкәләрен чагылдырырга , аның тормыш тәҗрибәсе кысаларына сыярлык булырга тиеш. Тыңлап-аңлауны оештыруның башлангыч чорында өр-яңа мәгълүматны үз эченә алган текстларны тыңлау чиктән тыш авыр бурыч булып тора, шул ук вакытта, бертөрле яңалыкны да чагылдырмаган текст та тыңлаучының игътибарын җәлеп итмәячәк.

Мотивация тудыру өчен актив тыңлау ихтыяҗы тудырырлык биремнәр кулланырга мөмкин. Мисал өчен, бик таныш булган әкият герое сурәтләве буенча текстка иллюстрация сайлап алу. Таныш материалга нигезләнеп кыска-кыска диалоглардан файдаланырга мөмкин. Шул ук вакытта әңгәмә барган

урынны ачыклау, анда катнашучыларның нинди һөнәр ияләре булуларын билгеләү кебек әңгәмәдә турыдан-туры чагылыш тапмаган мәгънәне ачыклау характерындагы биремнәр дә китерелергә мөмкин. Диалогларны актив куллану аның табигый аралашу текстларының типик формасы булуы белән аңлатыла. Мондый төр аралашу билгеле бер шартларда, үз алларына билгеле бер коммуникацион бурычлар куйган конкрет кешеләр арасында алып барыла.

Шулай итеп, тыңлап аңлауга өйрәтү өчен текстлар төзегәндә, сайлаганда сан (күләм) характеристикасын да игътибарсыз калдырыга ярамас. Укучы кабул итә ала торган текстның күләме — ул шартлы күрсәткеч һәм бертөркем факторларга бәйле (сөйләм кимчелекләре, сөйләм темпы, аның чыганагы), шуларның иң мөһимнәре булып тыңлана торган текстның эчтәлеге укучыларның мәнфәгатьләренә туры килү яки туры килмәве, мотивация һәм текстның мөмкин кадәр тулы дәрәҗәдә аутентик үзенчәлекләрен саклаулары тора.

Сөйләмгә өйрәтүдә текст

Телне өйрәнү сөйләмгә өйрәнүдән башлана. Сөйләм эшчәнлегенең бу төренә укуга бирелгән вакытның бик күп өлеше бирелә: турыдан-туры сөйләмгә өйрәткәндә дә, гамәлгә ашыруның төп шарты булып, эчке кабатлау торган тыңлап аңлауга өйрәнгәндә дә, укыганда да. Моннан тыш уку һәм тыңлап аңлау белем бирүнең мөстәкыйль максаты буларак каралмыйча, сөйләмгә өйрәтү чарасы буларак каралган очраклар да күзәтелә. Мондый очракта укылган яки тыңланган текст әлеге процессның әһәмиятле бер чылбыры буларак карала. Текст укучы әйтер дип көтелгән фикернең моделе буларак та кулланылырга мөмкин. Шулай ук телдән фикер алышуга нигез булган мәгълүмат чыганагы ролен дә үтәргә мөмкин.

Методикада традицион рәвештә репродуктив һәм продуктив сөйләмне аерып чыгаралар. Репродуктив сөйләмдә укучыларның сөйләмендә ижадилык күзәтелми, сөйләмнең барлык параметрлары бирелә: эчтәлеге, фикерне җиткерү тәртибе, тел чаралары. Бу, нигездә, ятланган текстны сөйләп чыгу, кайбер очракларда сизелмәслек дәрәҗәдәге үзгәрешләр белән. Башлангыч чорда репродуктив сөйләм лексиканы, грамматик структураларны үзләштерү, аларны куллану чарасы буларак әһәмиятле роль уйный. Продуктив сөйләм исә, киресенчә, укучының югарыда әйтелгән чараларны сайлаудагы мөстәкыйльлеге, интерактив булуы белән характерлана.

Сөйләм тексты мәсьәләсе җентекле рәвештә Е.И. Пассов тарафыннан өйрәнелгән. Ул мондый характердагы өйрәтү текстының уку өчен бирелгән

тексттан аермысын аның тулысынча телдән сөйләм билгеләренә ия булуында һәм язма формада чагылыш табуында күрә.

Әгәр дә уку һәм тыңлап аңлау текстларының төп максаты текстны аңлау, аннан яңа мәгълүматны эзләп таба белү булса, сөйләмгә өйрәтү өчен сайланган текст өр-яңа үз текстыңны барлыкка китерү максатына ирешү өчен нигез функциясен башкара. Сорауларга җавап һәм текстны сөйләп чыгу, һичшиксез, уку процессында мөһим роль башкаралар, әмма алар сөйләм процессы күнегүләре генә булып торалар. Сөйләм тексты, шулай итеп, мәгълүмати, эмоциональ бай булуы, эчтәлегенең укучылар дөньясына якын торуы белән аралашуга этәргеч тудырырга тиеш.

Телгә өйрәтүдә диалог мөһим роль үти, бигрәк тә башлангыч чорда. Кабатлаулар төрле структур модельләрне истә калдырырга ярдәм итә. Диалог сөйләм теленең үрнәге булып тора һәм Д. Жирар фикеренчә [2], укучыларга диалогтагы охшаш ситуацияләрдә файдаланырлык тел материалын (лексика, һәм структуралар) тәшкил итә.

Башлангыч чорда сөйләмгә өйрәтү үзләштерелергә тиешле лексиканы һәм грамматиканы җентекле рәвештә сайлап алуны сорый. Э.Й.Роовет “текст минимумы” дигән төшенчәне тәкъдим итә [3], ягъни үрнәк текстларның сан ягыннан чикләнүе максималь коммуникатив бурычларны үтәргә һәм коммуникатив осталыкка ия булырга мөмкинлек бирәчәк, дигән фикерне алга сөрә.

Язуга өйрәтүдә текст

Башлангыч этапта язу беренче чиратта лексика, грамматика һәм телдән сөйләмгә өйрәтү чарасы булып тора. Укучыларга кыска бәйләнешле текстны ишетеп яза белү яки кыска гына хикәя төзеп язу таләбе куела. Диктантның тексты тулысынча таныш материалга, язылышы таныш булган сүзләргә нигезләнә. Өйгә бирелгән сочинение темалары , кагыйдә буларак, балаларның көндәлек тормышлары һәм шәхси тәҗрибәләре белән бәйле була (“Минем бер көнем”, “Минем гаиләм”, “Минем яраткан дүрт аяклы дустым” һ.б.). Сочинениенең нигезен дәреслектә китерелгән, кирәкле тел материалын үз эченә алган һәм иншалауның билгеле бер эзлеклелеген чагылдырган текст хезмәт итә.

Кызганычка каршы, язуга өйрәтү алдагы этапларда да әлеге таләпләрдән ерак китми, куелган бурычлар тел аша хезмәттәшлеккә китерми. Әйтеп үтелгән үрнәк нигезендә, бирелгән темаларга диктант, изложение, инша язу — интерактив үзенчәлекләре булмаган эшчәнлек булып тора. Шуңа күрә язу эшчәнлегенең мондый формаларын интерактив формалар белән алмаштыру бик мөһим. Шундый формаларның кайберләренә тукталып китик.

Диктант өчен билгеле күләмдә бәйләнешле текст сайлап алганда, аның эчтәлеге укучыларны кызыксындырырлык һәм җиңел аңлашырлык булганда, язар алдыннан, шул текст бөтен килеш укылып, эчтәлеге укучыларга җиткерелгәндә, шулар өстенә, дөрес язылышы ачыкланып җитмәгән очракларга карата алдан аңлатма бирелгәндә, диктантлар дөрес язарга өйрәтү чарасына әвереләчәкләр.

Диктант үзенең җитди эчтәлеге һәм мөстәкыйльлек сферасының чикләнгәнлеге белән башка төр язма эшләрдән аерылып тора. Шушы үзенчәлеген исәпкә алмый эш иткәндә, диктант язу механик бер эшчәнлек төренә әйләнеп калырга мөмкин. Моңа юл куймас өчен, диктант үткәрү эшенә иҗади якын килергә, аның алымнарын активлаштырырга, аны, балалар рухына ятышлы, мавыктыргыч өстәмә чаралар белән баетып, иҗади эшчәнлеккә тарта торган зәвыклы эшкә әверелдерергә кирәк.

Моңа түбәндәге чаралар ярдәмендә ирешергә мөмкин:

1) текстны укыр алдыннан, аның авторы (чыганагы), әһәмияте турында кыскача аңлатма бирү, укучыларның игътибарын өзекнең сәнгатьчә эшләнешенә юнәлтү;

2) текст эчтәлегенең эмоциональ кабул ителешенә ярдәм итү;

3) өстәмә сораулар биреп, текстның эчтәлеге, идеясе белән кызыксындыру;

4) орфограммаларның язылышы, орфоргафия кагыйдәләренә нигезләнеше турында укучыларның үзара сорау-җавапларын оештыру;

5) текстка бүлек башы уйлап табу;

6) югары классларда иҗади диктант текстларын өстәмә биремнәр белән катлауландыру (мәсәлән, бәйләнешле текстның эчтәлегенә ярашлы эпиграфлар уйлап табу, эчтәлеккә бәйләп булырлык очракларда текстны цитаталар, афоризмнар, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән баету һ.б.).

Барлык диктантларны ике төркемгә аерырга мөмкин:

1) бер генә функцияле диктантлар төркеме: а) орфографик диктант, б) грамматик диктант;

2) катнаш функцияле (интерактив) диктантлар төркеме: а) иҗади диктант һәм б) ирекле диктант.

Интерактив диктантларның текстлары тормыштагы көндәлек вакыйгаларны чагылдыруга нигезләнгән була. Алар, гади (беренче төркем) диктантларга хас функцияләрне үтәү белән бер үк вакытта, укучыларның сөйләмен үстерү, теге яисә бу вакыйганы үзенчә күзаллау, бәяләргә өйрәтү, аларның иҗади мөстәкыйль язма эшләргә әзерләү бурычларын башкара. Бу

бурычлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) диктант тексты буенча укылган абзацларның эчтәлеген истә калдырып, аларны мөмкин кадәр оригиналдагы сүз һәм тәгъбирләр белән (өлешчә, үз сүзләре белән) язып бетерергә күнектерү; 2) диктант текстының лексикасын, грамматик, стилистик төзелешен, синтаксик конструкциясен үзгәртеп, текстны иҗади үстереп яза белергә өйрәтү.

Ирекле диктантлар — укучыларның орфографик, грамматик, лексик, стилистик һәм пунктуацион грамотасын ныгыту чарасы да, сөйләм сәләтен үстерү чарасы да алар. Ирекле диктантлар укучыларны мөстәкыйль язма эшләргә әзерләү (мисал өчен изложение язарга өйрәтү) чарасы буларак әһәмиятле урын тоталар.

Эшкә керешер алдыннан укытучы текстны тулысынча яки аерым өлешләрен төшереп калдырып (башын, уртасын, азагын) укып чыга (кирәк булса, кереш сүз әйтә), текстны яхшырак төшенергә ярдәм итердәй мәгълүматлар китерә, шулар аша укучыларны әсәр белән кызыксындыру максаты куялар. Текстны беренче кат укыганда, мәгънә егәрлеге көчлерәк булган сүзләр, сүзтезмәләрне, әһәмиятле грамматик берәмлекләрне махсус интонация ярдәмендә ассызыклап барырга киңәш ителә. Текстны укыганнан соң, аның эчтәлегенә анализ үткәрелә: укучыларның игътибары текстта хикәяләнгән вакыйгаларга, тасвирланган күренешләргә юнәлтелә, эчтәлектәге үзәк моментлар белән икенче дәрәҗәдәге детальләрне билгеләү ысуллары, аларны бер-берсеннән аера белү юллары күрсәтелә. Текстка шул рәвешчә анализ үткәрелсә, аның эчтәлеген тулы итеп үзләштерүгә җирлек барлыкка киләчәк.

Диктант текстында укучыларга таныш булмаган яки мәгънәсе ачыкланып җитмәгән сүзләр булырга мөмкин. Укучыларга аларның мәгънәсен, мәгънә төсмерләрен ачыклап бирергә кирәк.

Текстны өлешчә укып чыккан очракта, укучы аны үзе иҗат итеп язып бетерергә тиеш була.

Ирекле диктант максат, бурычлары, кайбер үтәү алымнары белән изложениегә якын тора. Шуңа күрә изложениегә карата бирелә торган иҗади биремнәр билгеле бер дәрәҗәдә ирекле диктантларга карата да куела.

Язма эш барышында укытучы һәр абзацны аерым-аерым бер генә мәртәбә укып бара. Укучылар һәр абзацның эчтәлеген үзләре аңлаганча һәм хәтерләрендә калганча язалар. Әйтелгән абзацлардагы җөмләләр саны укучылар язмасында артыграк та кимрәк тә булырга, шулай ук җөмләләрдәге кайбер сүзләр дә якынча мәгънәдәгеләре, синонимнары, эквивалентлары белән алмаштырылырга мөмкин. Мөһим шарт булып, аларның эчтәлеген дөрес бирү

булырга тиеш. Диктант язар алдыннан текстның эчтәлеген аерым өлешләргә бүлеп сөйләтү алымын кулланмаска тәкъдим ителә. Бу алым укучыларның игътибарын төп эштән читкә алып китә. Ирекле диктант үткәрү алымнары, бу төр диктант биремнәре һәм текстларының кайбер үрнәкләрен китереп китәбез:

1. Текстның эчтәлеген язарга, андагы табигать тасвирларын, мөмкин кадәр тулырак итеп, тексттагыча бирергә.

2. Текстның эчтәлеген язарга, автор текстының синтаксик төзелеш үзенчәлеген сакларга һ.б.

Текстның эчтәлек бөтенлеген саклаган хәлдә, аның лексикасын, грамматик төзелешен, синтаксик конструкциясен һәм стилистик мәгънә төсмерләрен төрле ысуллар ярдәмендә үзгәртеп һәм иҗади үстереп язарга күнектерә торган диктант иҗади диктант дип атала. Исеменнән үк аңлашылганча, бу төр диктант укучыларга иҗади биремнәр тапшыру юлы белән үтәлә. Диктант язарга керешер алдыннан, укучыларга диктантның темасы, максаты, биремнәренең эчтәлеге белдерелә, аларны үтәү юллары күрсәтелә.

Иҗади диктант биремнәренең кайбер үрнәкләре:

1. Эчтәлеккә туры килердәй итеп, аерымланган иярчен кисәк хәлләр өстәп, җөмләләрне үзгәртеп языгыз, тиешле урынга тыныш билгеләре куегыз (Язгы кояш тирә-юньгә якты нурларын сипте. — Язгы кояш, болытлар арасыннан чыгып, тирә-юньгә якты нурларын сипте.)

2. Җөмләнең теге яки бу кисәгенә аныклагычлар өстәп, аларны эчтәлек һәм мәгънә ягыннан яраштырып, текстка үзгәреш кертеп языгыз (Шагыйрь Муса Җәлилне хөрмәт белән искә алабыз. — Шагыйрь Муса Җәлилне, халкыбызның турылыклы улын, хөрмәт белән искә алабыз.)

3. Җөмләләрнең баш яки иярчен кисәк булып килгән кайбер сүзләрен антонимнары белән алмаштырып (ягъни җөмләләрне эчтәлек ягыннан капма-каршы вариантларга әйләндереп), текстны үзгәртеп языгыз; антоним җөмләләрне сызык аша күрсәтә барыгыз (Былтыр яз явымсыз килде — Быел көз явымлы булды.) һ.б. Моннан тыш интерактив нигездә үткәрергә мөмкин булган түбәндәге диктант формаларын ассызыклап китәсебез килә (Саба муниципаль районы “Урта гомуми белем бирү мәктәбе - сәләтле балалар өчен интернат”ының югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Галимҗанова Сания Вагыйзовнаның эш тәҗрибәсеннән).

Көйле диктант. Максат — укучыларның игътибар белән тыңлау күнекмәләрен үстерү, аңлап һәм дөрес язуларына ирешү.(Исем сүз төркемен йомгаклаганда үткәрергә була: санны, килешне,тартымны, җөмләдәге

функциясен билгеләргә мөмкин.) Бирем: С.Фәтхетдинов башкаруында “Мин яратам сине, Татарстан” җырын тыңлап, ялгызлык исемнәрне язарга кирәк.

Тавышсыз диктант. Максат: укучыларның игътибарлылыгын һәм күзәтүчәнлекләрен үстерү. Эш барышы: укытучының төрле хәрәкәтләр ясавына карап, укучылар сүзләрне үзләре яза (фигыль сүз төркемен өйрәнгәндә үткәрергә мөмкин: зат-сан, заман, барлык-юклык, юнәлешләрен билгеләү максаты куела. Шул фигыльләр белән берәр темага бәйләнешле текст төзетергә мөмкин)

Дуслык диктанты. Сыйныф биш-алтышар кешедән торган төркемнәргә бүленә. Укытучы өстәленә диктант тексты куела. Һәр төркемнән бер укучы чыгып, диктантның ике-өч җөмләсен хәтерендә калдырып, үзенең төркеменә кайта. Диктантны истә калдыру өчен 20-30 секунд вакыт бирелә. Текст белән танышкан укучы үзенең төркеменә әйтеп торып яздыра. Диктантны яздыручы укучы кайбер сүзләрне оныткан очракта төркемдәгеләр үзара фикерләшеп язып бетерәләр. Мәсәлән, түбәндә бирелгән текстны яздырырга мөмкин.

МАКТАНЧЫК АЛМА

Бакчада бер алмагач үсеп утырган. Аның әле бер генә тапкыр да алма биргәне булмаган. Яз җиткәч, бер генә бөртек чәчәк аткан да алмага бөреләнгән. Олы агачлар бик сөенгәннәр, кортлар ияләшмәсен өчен, көндез дә, төнлә дә аны саклаганнар. Алма көзгә бик матур булып кызарып пешкән. Уңыш җыяр вакыт җиткәч, аны да агачыннан өзәргә булганнар. Ләкин Алма:

— Мин, матур алма, өзеп ашар өчен түгел! — дигән дә яфраклар арасына кереп качкан. Шулай берзаман бөтен бакчага бер Алма булып калган. Шуннан соң ул:

— Күрдегезме инде, куркаклар, мин матур гына түгел, батыр Алма да бит әле! — дигән.

— Курыкмыйча, шундый зур бакчада минем кебек батырлар гына кала!

Бүтәннәр аның соңгы сүзләрен ишетмәгәннәр. Аларның кышка әзерлек эшләре башланган: яфракларын коясы, ботакларын корткыч бөҗәкләрдән чистартасы булган.

Шул арада күптән инде җай гына чыкканын көтеп торган алма корты сиздермичә генә менгән дә Алманы тешләп алган. Алма, авыртуына чыдый алмыйча, үрле-кырлы сикергән дә, агачыннан өзелеп, җиргә төшкән. Бер генә түгел, әллә нихәтле корт кимереп бетергән үзен.

Текстлар һәм интерактив биремнәр

(алда тәкъдим ителгән интерактив эш алымнарына нигезләнеп, укытучы биремнәрне үзгәртә дә ала)

Текстны укыгыз, биремне үтәгез**.**

Куян

Абый урманга барды. Ул урманнан куян тотып кайтты. Безнең дә кроликларыбыз бар. Куянны кроликлар янына куйсак, нишләр икән? Без куянны кроликлар янына яптык та читтән генә күзәтә башладык. Дуслашып китәләрме, юкмы? Юк шул, дуслаша алмадылар. Нинди кызганыч, бичара! Бер почмакта тик тора. Без анны кырга алып чыктык та урманга таба җибәрдек. Куян бар көченә чабып китте.

(НигъмәтИсхаков буенча.)

1	Куянны мин алып кайттым.	ЮК
2	Куян кырда яши иде.	ЮК
3	Куян белән кролик дуслаштылар.	ЮК
4	Куян белән кроликны бер читлеккә яптык.	ӘЙЕ
5	Куян бик кызганыч иде.	ӘЙЕ
6	Куян читлеккә ияләште.	ЮК
7	Без куянны кире урманга җибәрдек.	ӘЙЕ
8	Куян акрын гына урманга кереп китте.	ЮК

Бирем. Текстны укыгыз. Таблицадагы фикернең дөрес яки дөрес булмавыннан чыгып ӘЙЕ, ЮК җавапларының берсен сайлагыз.

Текстны укыгыз, биремне үтәгез.

_____ _____

Кичтән әле ул-бу юк иде. Мәктәптән кайтканда, без кара җиргә басып кайттык. Ә менә иртәгесен дөнья үзенә бертөрле ямьгә төренеп уянды.

Безгә яңа шатлыклар алып килүче, керфекләребезгә кунып, безнең белән урамда бәйрәм итеп йөрүче _____ _____, сәлам, сәлам сиңа! Син шулай әкрен генә ява тор, мин синең килүең турында белгән-күргән кешеләргә, дусларга хәбәр итеп, сөенче алып йөрим. *Ф.Хөсни*

Бирем. Текстны укыгыз, төшеп калган сүзләрне уйлап языгыз. Текстка исем бирегез

Укыгыз, биремне үтәгез.

Җөмлә	Тәртип саны
Безне шатланып каршы алдылар.	
Әби самовар куйды.	
Ашап бетергәч, әбигә рәхмәтләр әйттек.	
Әби күчтәнәчләр биреп, безне озатып калды.	
Кышкы каникуллар башланды.	
Самовар җырлый-җырлый өстәлгә килеп басты.	
Без үзебезне өстәл артында бик әдәпле тоттык.	
Мин энем Рөстәм белән кышкы каникулда әбиләрдә кунакта булдым.	
Самовар артыннан ит сумсалары, алма, конфетлар, хуш исле бал өстәлгә куелды.	

Бирем. Җөмләләрне текст килеп чыгарлык тәртиптә урнаштырыгыз.

ҖИЛ БЕЛӘН КОЯШ

Бервакыт мөлаем Кояш белән кырыс Җил бәхәсләшә башлаганнар. Кайсыбыз көчлерәк, янәсе. Озак бәхәсләшкәннәр, әмма барыбер бер фикергә килә алмаганнар.Юлдан атлы сәяхәтче узып бара икән. Күр дә тор, — дип гайрәтләнгән Җил, шуңа күрсәтеп. — Күз ачып йомганчы өс киемен салдырам мин аның.Шулай дип, Җил бар көченә тузына башлый. Ләкин, күпме генә тырышмасын, сәяхәтченең киемен салдыра алмый. Тегесе, киресенчә, аның саен ныграк төренә генә бара. Җилнең ачуы кабара: котырганнан-котыра, карлы-бозлы яңгыр яудыра башлый. Юлчы бирешми, бишмәтен төймәләп, билен ныгытып буып куя. Шунда Җил бу кешенең киемен салдыра алмаячагын аңлый.

Кояш, Җилнең көчсезлеген күреп, елмаеп җибәрә. Болытлар арасыннан килеп чыга да нурлары белән җирне дә киптерә, юлчыны да җылыта. Анысы, Кояшка рәхмәт укый-укый, артык киемнәрен иярге үк бәйләп куя. Менә күрәсеңме, — ди Кояш пырдымсыз Җилгә, — усаллыкка караганда яхшылык белән күбрәк нәрсәгә ирешеп була икән бит (К.Ушинскийдан).

Биремнәр: текстны абзацларга бүлегез. Бүлгән абзацларны мәгънәләре буенча төркемләгез.

Текстның үзегез билгеләгән абзацлары буенча хикәя төзеп языгыз (сөйләгез).

ТУГАН ИЛЕМ

(Истәлекләрдән)

Минем әнием йокыдан бик иртә, кояш чыкканчы ук торучан иде. Беркөнне мин дә шулай иртә тордым... Әни миңа сөтле чәй эчерде. Балчык чүлмәктә кайнаган сөт өстенә кызгылт каймак утыра. Каймак астындагы сөт гаҗәп тәмле, чәе дә эчеп туймаслык була торган иде.

Шушы чәй минем тормышымны уңай якка хәл итте: мин, кояш чыкканчы торып, әни белән тәмле чәй эчә торган булдым. Иртә торырга шулхәтле күнектем, кояш чыкканда йоклап ята алмый башладым.

Соңрак, шәһәрдә яши башлагач та, иртә тора идем. Хәзер дә, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы уянып, үзенчә эшкә керешкәндә, мин инде язарга утырган булам.

Еш кына башыма мондый уй килә: көн саен шулай кояш белән торсак! Күпме сәламәтлек, шатлык, бәхет өстәлер иде кешеләргә!

Чәйдән соң мин ауга китәм...

Авым минем, һәрвакыттагыча, табышлардан гыйбарәт.

Табигатьтә әле үзем күрмәгән, ихтимал, моңа кадәр беркем дә юлыкмаган нәрсәләрне табарга кирәк миңа...

Яшь дусларым! Без — табигатьнең хуҗалары. Табигать безнең өчен — кояш хәзинәсе. Без аны сакларга, алый гына да түгел, яңадан-яңа байлыкларын табып, өйрәнеп, серенә төшенергә тиеш.

Балыкка чиста су кирәк — сулыкларны сакларбыз. Ураманнарда, кыр-далаларда, тауларда кыйммәтле, сирәк җәнлекләр яши — урман-кырларыбызны, тауларыбызны сакларбыз. Балыкка — су, кошка — һава, җәнлекләргә урман-кырлар, дала-таулар кирәк. Ә кешегә Туган иле кирәк. Табигатьне саклау — Туган илеңне саклау дигән сүз ул.

Биремнәр. Укытучы текстны бер генә кабат укып чыга. Укучылар хәтерләрендә калдырырга тырышалар. Аннан соң укытучы текстны аерым өлешләргә бүлеп язылган карточкалар тарата. Укучылар ул өлешләрнең дөрес тәртибен табып төзергә тиешләр. Шуннан соң һәр укучы тәртип буенча үзәлешен укып, тулы текст яңгыратыла. Азактан укучылар тексттагы тарихка охшаш хикәя төзеп язалар.

ТАУ ТАПТЫМ

Кичә мин тау таптым. Бүген дә шул тауга шуарга барам. Берүзем генә барам. Инде мин зур бит.

Әнкәй елмаеп тәрәзәдән карап калды. Ул минем зур икәнне белә.

Күрше Гайнулла бабай да, олы борынын тәрәзәгә төртеп үк, миңа карап калды.

Мин ераккa китеп шуам, юлның теге ягына. Ә-нә теге җиргә хәтле барам. Кичә дә шунда барган идем. Шунда мин үземә яхшы тау таптым. Чаңгым да яхшы.

Кар тирән. Карда бик күп эзләр бар. Төлке, бүре эзләре, диләр. Монда поши эзләре дә була, дип сөйлиләр. Мин үзем куян эзләрен генә таныйм әле, әтием күрсәтте.

Бүген көн салкын. Җил дә юк. Бөтен җир ап-ак! Өченче көн инде шулай. Мондый көннәрне мин санап барам.

Җайлап кына кар ява башлады. Кар яуса, көн җылыта, дигән иде әти. Җылытыр, ахры.

Монда җәй көне нинди җылы иде! Чәчәкләр бар иде. Ак, зәңгәр, сары, ал чәчәкләр... Күбәләкләр!

Мин ак күбәләкләрне яратам. Кар бөртеге, ак булса да, күбәләк була алмый. Кыш көне күбәләк кар була, боз була...

Ә минем кулым да өшеми. Яңа бияләйләр кигәнгәдер инде. Әллә җылыта да микән?

Кара-кара! Кар бөртекләре ничек күп булып ява башлады!.. Әнә нинди эзләр күмелә! Бүре эзләредер әле, күмелсеннәр тизрәк. Алар мине бераз куркыта. Куян эзләреннән мин курыкмыйм. Тик куян эзләре күмелеп тә бетте шул инде... Кар һаман ява. Моннан безнең өебез күренеп тора. Әткәй эштә инде. Әнкәй әле тәрәзәдән карый микән? Гайнулла бабай да карыйдыр. Алар мине күрә микән? Хәзер мин үзем тапкан тауга менәм. Яңа карга яңа эз салам. (Рөстәм Мингалим)

Бирем. Текстның төшереп калдырылган өлешен өстәп языгыз. Укытучы текстны укый. Курсив белән бирелгән өлеше укылмый. Укучылар шул өлешен үзләре уйлап язалар. Берничә укучы үзләренең вариантларын укый, ни өчен шулай дәвам итүен аңлата. Соңыннан автор язган вариант белән чагыштырыла.

ШУКТУГАН

Күл буенда тамыр җәйгән биек наратта карт тукран — Тук-тук бабай йокысыннан уянды. Аның томшыгы без кебек үткер, ук кебек җитез. Әлеге

нарат кәүсәсендәге тишектә ул үзенә уңайлы оя корган. Җәен-кышын шунда яши.

Тук-тук бабай урмандагы агачларны дәвалый. Үзенең без-томшыгы белән агач кайрысын тишә дә аннан корткыч бөҗәкләрне чүпли.

Тук-тук бабай белән бергә аның Шуктуган исемле оныгы да яши.

Тук-тук бабасы Шуктуганны күреп алды.

• Әйдә, улым, тизрәк, кил минем яныма! Урманны коткарырга булыш! — дип кычкырды ул аңа.

Менә Шуктуган бабасы янәшәсендә нарат ботагына барып кунды. Тырнаклары белән кайрыга ябышты, койрыгын агач кәүсәсенә терәде. Кайры астыннан бер кортны, аннары икенчесен, өченчесен чокып чыгарды...

Шулай итеп, кошлар көне буе тир түгеп эшләделәр. Кичкә кадәр урманда бер корткыч та, бер хәшәрәт тә калмады.

Ә иртәгесен үле урман яңадан шаулап-гөрләп яши башлады. Җиләс җил ак каеннарның, шыбырдык усакларның яфракларын лепердәтеп уйнады. Шаян күбәләкләр чәчәктән чәчәккә кундылар. Куян балалары яшел үлән арасында мәтәлчек атыштылар. Йөнтәс аю, кызы белән малаен ияртеп, күлгә су коенырга килде. Керпе үзенең нәниләрен сыйлар өчен йөгерә-йөгерә гөмбә җыйды, ап-ак сабаклы гөмбәләрне үткер чәнечкеләренә кадап оясына ташыды.

— Менә шулай, улым! — диде Тук-тук бабасы Шуктуганга. — Син хәзер зур инде. Үзең азык таба аласың, агачларны да үзең дәвалый беләсең. Хәзер без синең белән бергәләп корткычларга каршы көрәшербез, урманыбызны саклырбыз. (Ж. Тәрҗемановтан)

Бирем. Текстның төшереп калдырылган өлешен өстәп языгыз. Укытучы текстны укый. Курсив белән бирелгән өлеше укылмый. Укучылар шул өлешен үзләре уйлап язалар. Берничә укучы үзләренең вариантларын укый, ни өчен шулай дәвам итүен аңлата. Соңыннан автор язган вариант белән чагыштырыла.

ДИРИЖЕРЛЫК ТАЯКЧЫГЫ

Татарстан Республикасының дәүләт музеенда даһи композиторның хәтта үз исеме белән аталган музеенда да булмаган бик тә кадерле бер ядкарь — аның дирижерлык таякчыгы саклана икән. Салих Сәйдәшевның мемориаль музее ничәмә-ничә тапкырлар гозерләп сораса да, дәүләт музее исә әлеге затлы экспонатыннан аерылырга теләми икән.

Бу яңалык миндә кызыксыну уятты: таякчыкның бер-бер хикмәте булса кирәк. Бәлки ул бик тә затлы, бары тик диңгез арты илләрендә генә үсә торган агачтан эшләнгәндер? Бәлки ул асылташлар белән бизәлгән фил сөягеннәндер?

Юк, диңгез арты илләрендә генә үсә торган агачтан да, асылташлар белән бизәлгән фил сөягеннән дә эшләнмәгән иде ул. Гап-гади, кайрысы кесә пәкесе белән юнылган утыз сантиметр озынлыгындагы бераз кәкрерәк тал чыбыгы иде бу! Скрипка һәм янә дә дистәләгән башка төрле нәзберек, гаярь вә дәртле-моңлы уен кораллары белән идарә итүче даһи кулына килеп эләгәсен каядыр Мишә буенда үскән бу тал чыбыгы чамалады микән?!

...Аны мөгаллимнең күрсәткеч таягына да охшатып була. Менә таяк мәктәптәге иске география картасы буйлап, илләр һәм океаннар аша уза, бөек калаларга килеп төртелә, елга-күлләрне сыйпап үтә. ...Озак кулланудан шомарып беткән әлеге дирижерлык таякчыгына янә текәлдем. Гап-гади тал чыбыгы да даһи кулында тылсымлыга әверелә икән ләбаса! (180 сүз)

Бирем. Укытучы текстны абзацлап укый, бер генә кабат. Укучылар хәтерләрендә калдырып, мөмкин кадәр оригиналга якын итеп язарга тиеш булалар.

КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК

Безнең солдатлар иртәнге ашны ашап кына бетергәннәр иде. Кинәт югарыда, окоп өстендә, мәче тавышы ишетелде. Бер сержант саклык белән генә торып караган иде, анда кечкенә генә соры песи баласын күреп алды.Шундый салкын көндә песи баласы килсен, имеш. Әйләнә-тирәдә кара урман. Алда ерак түгел генә бер авыл күренә. Бу авылның өйләре сугышта җимерелеп беткән. Тик ара-тирә җимерек өйләрнең бүрәнәләре генә тырпаеп торалар иде.Бу авыл фашистлар кулында. Песи баласы, азык эзләп, кешеләр янына килгән булырга кирәк. Әйтерсең ул да ерткыч фашистлардан качкан. Песи баласы, окопка керүгә, кызганыч тавыш белән мияулап җибәрде. Кунакка аш салып бирделәр. Ашагач, аның күзләре матурланып китте, әзрәк уйнады да почмакка барып йокларга ятты.Песиләр торган җирләрен сагынучан булалар. Әлеге сержант песи баласын алды да окопның кырыена куйды. Песи әзрәк басып карап торды да авылга таба йөгерде.Икенче көнне иртән песи баласы тагын окопка килде. Бу юлы инде ул мияуламыйча гына окопка үзе сикереп төште һәм тиз генә савыты янына килеп ашый башлады. Песи баласы безнең солдатларга ияләшеп китте. Көн дә иртә белән килә дә, кичкә кадәр окопта йоклап, тамагын туйдырып, кич белән үзенең туган авылына кайтып китә торган булды. Сержант, песи баласын авылга озаткан вакытта, һәрвакыт аның аркасына фашист солдатларына

мөрәҗәгать итеп язылган бер-ике листовка бәйләп җибәрә торган булды. (А. Шамов буенча)

Бирем. Текст экранга чыгарыла. Укучылар текстны абзацларга бүләләр һәм һәр абзацның эчтәлеген чагылдыра торган бер җөмлә төзеп язалар, шул рәвешле, хикәянең кыскача эчтәлеген чагылдыралар. Текст экраннан алына һәм укучылар бер абзацның эчтәлеген текстка мөмкин кадәр якын итеп язалар.

Сүзләрне тап!

Менә ... **кыш** килеп җитте. Бер-ике көн эчендә ... **кар** яуды. Бөтен тирә-як ак юрган астында калган кебек иде. Кыш җитүгә, урманда кошларга азык табу шактый кыенлашты.

Укытучыбыз Сания апа кошларга җимлекләр ясап куярга һәм анда нинди кошлар очып килүен күзәтергә кушты. Без моңа ... **риза булдык**. Мәктәптән кайткач, ... **җимлек** ясарга керештек.

Мин дә тактадан кечкенә генә өстәл һәм җимлек ясадым. Аны урман янындагы ... **чыршы** төбенә куйдым. Чыршының ... **ботаклары** җимлектәге азыкны кар басудан саклырлык иде. Җимлек әйбәт булып чыкты. Ул тәрәзәбездән дә күренеп тора әле. Дөресе шулай. Минем әтием урманчы булып эшли, шуңа күрә без ... **өйдә** яшибез.

Якшәмбе көн иде. Җимлегемә ипи, ярма, ... **миләшләр** салдым. Бер читтән генә карап тора башладым. Менә ике песнәк килеп кунды. Ярма белән икмәкне ашадылар да агач ботагына кундылар. Шул арада кызылтүшләр очып килеп җитте. Минем җимлегемдә алар өчен дә сый бар иде: аларга мин миләш асып куйган идем, рәхәтләнеп миләш чукыдалар ... **дусларым**. Миләш чыпчыгы да авыз итте минем җимлектәге азыктан. Ә чыпчыклар? Алар җимлектән китәргә ашыкмыйлар да әле. Кинәт җимлек өстендәге ботакка тиен сикереп менде. Ул да җимлектә рәхәтләнеп сыйланды.

Хәзер мин көн саен канатлы дусларыма җим бирәм. Кошлар да, тиеннәр дә рәхим итсеннәр. (Ш.Биккол буенча)

Бирем. Текст андагы төшереп калган сүзләрне өстәп язу максаты куеп укыла. Текстка исем уйларга һәм аны нигезләп язарга тәкъдим ителә.

КЫШ КӨНЕ ТАУДА

Кичә мин тау таптым. Бүген дә шул тауга шуарга барам. Үзем генә барам. Дусларымны көтеп, тау шуарга баруны сузасым килмәде. Мин, гомумән, табигатькә ялгызым чыгарга, ялгызым йөрергә яратам. Әнкәй елмаеп тәрәзәдән

карап калды. Күрше Гайнулла бабай да, олы борынын тәрәзәгә төртеп үк, миңа карап калды.

Мин ераккa китеп шуам, юлның теге ягына. Ә-нә теге җиргә хәтле барам. Кичә дә шунда барган идем. Шунда мин үземә яхшы тау таптым. Чаңгым да яхшы. Тирә- кар ап-ак, тирән. Ак кар өстендә бик күп эзләр бар (Р. Фәиздән).

Бирем. Текст укучыларга таратыла. Кар өстендәге эзләр турында язарга тәкъдим ителә.

Текст

Кызыксынулар һәм мавыгулар — һәр кеше тормышының мөһим өлеше. Яраткан шөгыльләр кешенең эчке дөньсын ачарга ярдәм итә, аның уникаль шәхес булуы турында сөйли. 3) Берәүләр — китап укырга, икенчеләр — рәсем ясарга,...

Мин фотога төшерергә яратам. Балачак____ бабамнан мирас булып калган иске "Зенит" фотоаппараты бар иде. Мин анда тормыш_____ кызыклы мизгелләр____, пейзажлар төшердем. Киләчәктә уңышлы фотограф булырга телим, шуңа күрә ... .

Икенче мавыгуым — рәсем ясау. Элек сәнгать мәктәбе_____ йөрдем. Мин табигатькә чыгарга, матур күренешләрне альбомга төшерергә яратам. Майлы буяу, акварель, акрил белән рәсем ясый беләм, ләкин ... . Рәсем ясаганда, тулысынча иҗат___ чумам һәм вакыт___ ничек узуын сизмим.

Мин балачактан биергә яратам. Хип-хоп, дэнсхолл, джаз-фанк кебек заманча биюләр белән шөгыльләнәм, шулай ук.... Кайвакыт без дусларыбыз белән урамда, кинотеатр янында яки парк мәйданчыгында биибез. Үтеп баручы кешеләр җыелып безгә карап торалар һәм кул чабып алкышлыйлар.

Шулай ук мин күп вакытым____ китап уку___ багышлыйм. Минем яраткан язучыларым — Куприн, Достоевский, Лев Толстой. Китаплар мине илһамландыра, уйлану өчен азык бирә. 20) Кайвакыт мин шигырьләр язам һәм дуслары_____ укып күрсәтәм. Дусларым ижатымны уңай бәялиләр һәм ...

Бирем.

Төшереп калдырылган сүздәрне һәм кушымчаларны язып бетер.

Текстка исем бир. Микротемаларга бүл

Текстның эчтәлегенә нигезләнеп диалог, полилог төзегез.

АЙДАР

Бу ятимнәр йортында әнисез яки әтисез балалар күп. Әтисез-әнисез балалар да бар. Кайберләренең әти-әнисе генә түгел, әби-бабасы, туган-тумачасы да юк. Анысы гына нәрсә... Айдарның туган көне дә юк хәтта. Барлыкка бар, тик дүрт елга бер генә килә. 29 нчы февраль көнне туган шул ул, кәбисә елны. Шуңа күрә, бер мәртәбә үткәрә дә, өч ел рәттән туган көнсез, бәйрәмсез яши. Бу балалар йортына килгәч, ул әле бер дә үткәрмәде туган көнен.

Ә ятимнәргә туган көн бик кирәк. Туган көннәрен билгеләүче балаларга бу көнне тәмле ризыклар бирәләр, яңа киемнәр кидерәләр, алар янына туганнарын, дусларын чакыралар... Иң мөһиме: бу көнне аларны кыйнамыйлар. Хәтта иң усаллардан саналган Хәмис тә андыйларга кул күтәрми. Шундый тәртип.

Кызганыч,быел да 28 февральдән соң 1 март килде. Быел да Айдар туган көнсез калды. Иртән торуга ук, түшәгенә капланып, елап алды. Юк, беркемгә дә рәнҗеп яисә үпкәләп еламады ул.. Бүген тагын кыйналасын белеп, шул кыйналган вакытта еламас өчен елады. Чөнки белә: алдан елап, күз яшьләреңне түгеп, күңелеңне бушатып куйсаң, соңыннан, ничек кенә кыен, авыр булса да, еламый калырга мөмкин. Артык горур шул ул. Хәмис аны күпме үз янына алырга, үзенә йомышчы итәргә тырышып карады. Айдар барыбер баш бирмәде, кыйналса — кыйналды, әмма Хәмиснең куштаны булмады. (Г. Гыйльманов буенча)

Бирем. Укытучы текстны укый. Укучыларга ассызыклаган җөмләгә нигезләнеп, фикерләрен язарга тәкъдим ителә.

Текстны укы. Биремнәрне үтә.

Туган илне сагыну дигән хис тә төрле дәрәҗәдә, төрлечә була икән. Менә син чит ил урамнарында ялгыз йөреп кара. Шагыйрь әйтмешли, син кем кадерлесе анда? Кинәт авырдың, ди. Докторга күренү өчен, күпме доллар кирәк? Синең өчен анда беркем дә җавап бирми, син анда берәүгә дә кирәк түгел. Чит дөньяның иң эре башкаласында, иң зур урамның уртасында син — ком бөртеге. Ватан дигән газиз җирне әнә шунда син бөтен нечкәлеге белән аңлый башлыйсың. Мин бу хисне күп тапкырлар дөньяның күп калаларында кичердем. Бу хис Римда, Тегеранда, Каһирәдә, Истанбулда, Коломбода, гомумән, бер җирдә дә минем күңелемнән китмәде. Чын сагыну үзен шунда танытты.

Безнең авылда яшьлеген Уральск шәһәрендә уздырган тегүче Гатият абзый бар иде. Ул заманында Тукайлар, Кариевләр белән таныш булган. Шул абзый сөйли торган иде: “Чит җирләрдә шунысы читен: үз авылыңның су буендагы ташына кадәр сагынасың”. Без, малайлар, аннан көлә идек. Су буендагы чыпчык ташын кем сагынсын? Ләкин без ашыгыбрак көлгәнбез. Гатият абзыйның бу сүзләрен мин хәзер яхшы аңлыйм.

Һәркемнең үз балачагы, үз шәһәре, үз авылы, үз чишмәләре, үз таулары бар. Һәркем дөньяда безнең шәһәрдән, авылдан, чишмәдән, таудан да матур урын юк дип ышанып яши бирә.

Җир шарында алты кыйтга бар һәм алар һәрберсе үзенчә матур. Әмма иң матуры, әлбәттә, син туган, син үскән җир.

(М. Мәһдиев)

Биремнәр

Текстка исем куй. Мәгънәви абзаөларын билгелә.

1).
2).
3).
4).

Дөрес раслауларны (+) билгесе белән, ә хаталыларын (-) тамгасы белән тамгала. ?

1). Хикәядә авторның туган илен сагынуы турында язылган.
2). Туган илне сагыну хисе барлык кешеләрдә дә бер төрле була.
3). Авылдашым Гатият абый Тукайны да Габдулла Кариевны да белгән.
4). Малайлар Гатият абый күңелендә яшәгән сагыну хисен яхшы аңлыйлар.
5). Елга буендагы ташны да сагынып була шул.
6). Балачак һәркемнең үзенеке.
7). Җир шарының барлык урыннары да күңелгә якын.
8). Туган җирне генә чын сагыну белән сагынып була.

МАҺИЯ ӘБИ

Автобус тигез юлдан, тузан туздырып, алга чаба. Кинәт юл читендә чандыр гына бер карчык күренде. Ул кәшимир яулык бәйләгән, ә өстендә кызыл бәрхеттән тегелгән камзул белән күлмәк, аягында бизәкле читек иде. Менә ул таягын өскә күтәрде. Шофёр егет автобусны шунда ук туктатты. Әби, рәхмәт укый-укый, минем яндагы буш урынга килеп утырды. Итәкләрен рәтләп, як-ягына каранып алды.

Татарча — монысын үз телем булганга, чувашча — күршеләр теле, русча белмәү гөнаһ инде, балам. Шуларга кушып, гарәпчә дә укыштырам. Әле Казахстан якларыннан кайтам. Сеңлем яши анда. Шунда казахлар белән дә рәхәтләнеп аралаштым. Тел бик кадерле нәрсә, телләр белү зур хәзинә ул,балам. Юкка гына халык: “Телләр белгән — дөнья гизгән,” — димәгән. Тик кешеләр шул тел белән бер-берсен рәнҗетеп кенә ялгышалар. (Г.Сабитовтан)

Бирем. Укытучы текстны укый һәм төшеп калган өлешен укучылар язып бетерергә тиешләр. Язылган өлешләрен укыйлар һәм ни өчен шулай язганнарын аңлаталар.

РАВИЛ ГАЕБЕН ТАНЫДЫ

Равил, мәктәптән кайткач,ашады, эчте дә, тимераякларын алып, урамга чыгып китте.Ул кузгалып китәргә торган автобус артына тотынып барырга теләде. Автобус кузгалды. Алдагы тукталышка җитәр алдыннан, Равил кулларын ычкындырды һәм юлның икенче ягына чыкты. Ләкин каршыга килә торган йөк машинасын ул күрмәде.

Кинәт кенә машина алдына килеп чыккан баланы күргәч, тәҗрибәле шофёр да каушады. Зур тизлек белән килгән машинаны туктатырга соң иде. Шофёр гәүдәсе белән рульгә ятты һәм машинаны тротуарга борды. Машина баганага бәрелде һәм туктап калды.Ә Равил алдына-артына карамыйча йөгерде.

Икенче көнне Равилнең күңеле тыныч, кәефе яхшы иде. Кичә булган хәлне ул исенә дә төшермәде. Әйтерсең, бернәрсә дә булмаган!

Зур тәнәфес вакытында Равил коридорда сыйныфташлары янына килде. “Хәзер әтине эшеннән чыгаралар”, — диде Сәлим, күңелсез генә. “Нәрсә булды? Ни өчен?” — дип сорады Равил. Аңа кичәге вакыйганы сөйләп бирделәр.

Равил бик борчылды, аның Сәлимнең әтисенә ярдәм итәсе килде. Иртән торгач, ул Сәлимнең әтисе эшли торган җиргә барды. Директор кабинетына керде, аның белән исәнләште дә: “Барый абый Сөләймановны эшеннән чыгармагыз, директор абый. Ул гаепле түгел!” — диде. “Ничек гаепле түгел? Ул бит машинаны ватты!” — диде директор. “Минем аркада ул,” — диде Равил һәм барысын да сөйләде.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Директор Сөләймановны чакыртты, машинага ремонт ясарга кушты. Сәлимнең әтисе эшендә калды (Ә.Дибаевтан).

Бирем. Текстны укытучы укый. Укучылар, Равил гаебен танымаган булса, Барый Сөләймәновның һәм аның гаиләсенең тормышы ничек дәвам иткән

булуы турында фикерләрен язалар һәм бер-берсенең эшләре белән танышалар, үзләренең фикерләрен әйтәләр.

УРМАНДА

Бүген алар урманга барырга уйладылар. Тирә-якка соклана-соклана сукмактан кереп барганда, Гөлнара кычкырып җибәрде: «Ә без бит әле урманнан рөхсәт сорамаган!» Бу сүзләрдән кайсы көлде, ә кайберләре тезелешеп басып: ...

Сыйныфташлары уйнаганда да, бәрәңге пешергәндә дә, ул эшчән кырмыскаларны карап, урман докторы тукранның тавышын тыңлап йөрде. Табигать барысын да аңлый, ә дус егетләре, кызлары ни өчен аңламыйлар соң аны?

Сәеррәк шул ул: башкалар кочак-кочак чәчәк җыйганда да Гөлнара ... ; иптәшләре агач ботагын сындырганда да... .

«Аерылып йөрү килешмәс», — дип, Гөлнара дуслары янына килде. Сөйләшеп, көлешеп утыргач, кәефе дә күтәрелеп китте. Кайтыр вакыт җитте. Алар җыена башладылар. Гөлнара консерв банкаларын, кәгазь кисәкләрен җыярга тотынды. Бер-ике иптәше дә аңа килеп кушылды. Урманны пычратып калдырырга ярамас! Кайбер сыйныфташлары: «Җыегыз, җый!» — дип көлештеләр. Әмма ул бер сүз дә дәшмәде, йөрәге әрнеп уйлады гына: ... .

Бирем. Текст укытучы тарафыннан укыла. Күп нокталар куелган урында укытучы туктап тора һәм укучыларга төшеп калдырылган өлешне язып бетерү максаты куя. Укучылар язган өлешләрен текст буларак формалаштыра.

БАЙЛЫК

Рахманның теләге — сәяхәтче булу. Сәяхәт турында китаплар укыды ул, илебез картасын биш бармагы кебек белә. Рахман үз илебездә генә сәяхәт итәчәк. Безнең илебез бөтенесенә дә бик бай. Рахман, сәяхәтләрдә йөреп,моңарчы билгеле булмаган байлыкларны кешелеккә бүләк итәр.

Туктагыз әле, нәрсә соң ул байлык? Беркөнне ул әтисеннән:

- Байлык нәрсә була ул, әти? — дип сорады.
- Кешегә кирәкле барлык нәрсә — байлык, улым. Менә бу өстәл дә, синең китапларың да — байлык. Ә төп байлык ул — икмәк. Әмма кешенең әле бернәрсә белән дә алмаштырмас (алыштырып булмас) байлыгы була. Беләсең киләме шуны?
- Беләсем килә!

Бирем.

Дөрес раслауларны “Д”, ялгыш раслауларны “Я” тамгасы белән билгеләгез.

1). Рахман география белән мавыга.

2) Ул сәяхәтче булырга хыяллана.

3) Ул чит илләрдә сәяхәт итәргә тели.

4) Рахман, тырышып, чит илләр картасын өйрәнә.

5) Ул туган иле буйлап кына сәяхәт итәчәк.

6) Туган илебез матур һәм бай.

7) Рахман байлыкларны үзенә алырга хыяллана.

8) Байлыкның нәрсә булуын аңа әтисе аңлата.

9) Рахманның әтисе байлыкның нәрсә икәнен аңлата алмый.

10) Рахманның алыштырып булмас байлыкның нәрсә булын беләсе килә.

МӘРМӘР ТАКТА

Татарстан Язучылар союзының вестибюленә мәрмәр такта куелган. Ул тактада Бөек Ватан сугышында үлеп калган утыз язучының фамилиясе язылган. Алар язасы әсәрләрен язып бетермичә, яшәргә өлгермичә үлгәннәр.

Польша җирендәге Згеш дигән кечкенә генә шәһәрдә“Тапшырылмаган хатлар” авторы Гадел Кутуй күмелгән. Фатих Кәрим җиңүгә ике ай кала Кенисберг янында һәлак була. Дахауның крематорий мичләрендә фашистлар Совет Армиясе полковнигы шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйне яндырдылар. Бу исемлектә җырлары бөтен планетага таралган легендар Муса Җәлил, аның көрәштәше Абдулла Алиш та бар.

Бирем.

Дөрес раслауларны “Д”, ялгыш раслауларны “Я” тамгасы белән билгеләгез.

1. Язучылар союзы бинасында мәрмәр такта бар.
2. Мәрмәр тактада барлык татар язуыларының фамилиясе язылган.
3. Утыз язучы Бөек Ватан сугышында һәлак булган.
4. Згеш шәһәрендә күп татар язучылары үлгән.
5. Згеш шәһәре — зур шәһәр.
6. Згеш шәһәре янында Гадел Кутуй һәлак булган һәм ул шунда күмелгән.
7. Ф.Кәрим “Тапшырылмаган хатлар” әсәренең авторы.
8. Ф.Кәрим Җиңү көне алдыннан гына һәлак була.
9. Хәйретдин Мөҗәй — шагыйрь һәм офицер була.
10. Абдулла Алиш Муса Җәлил белән таныш булмый.

Интерактив ысуллар кулланып башлангыч сыйныфларда үткәрелгән туган тел (татар теле) дәресләре үрнәкләре

Закирова Альмира Хәнәфи кызы,
Казан шәһәре Вахитов районы
муниципаль бюджет белем бирү
учреждениясе “96 нчы гимназия”
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

2 нче сыйныфның рус төркемнәрендә
“Йорт һәм кыргый хайваннар” темасы буенча татар теле дәресе

Максат:

1. Белем бирү: йорт һәм кыргый хайваннар турында гомуми төшенчә; хайваннарның охшаш һәм аермалы якларын карау; сөйләм калыбын аңлау һәм үзләштерү; укучыларның сүзлек составын баету.

2. Күнекмәләр булдыру: укучыларның сөйләм телен һәм фикерләү сәләтен үстерү; хайван атамаларын сөйләмдә һәм язуда дөрес куллана белү күнекмәләрен булдыру.

3. Тәрбия бирү: укучыларда хайваннарга карата миһербанлык һәм шәфкатьлелек хисләре тәрбияләү.

Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:

Регулятив УУГ: эшчәнлекне планлаштыра, үз алдыңа максат куя белү, эшләгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

Коммуникатив УУГ: парларда эшләгәндә үз фикереңне җиткерә белү, үзара килешү, мәгълүматларны таба, куллана алу, әңгәмәдә катнашу.

Танып-белү УУГ: дәреслектә ориентлаша белү, дәреслек, такта һәм карточкалардагы мәгълүматлар белән эшли белү.

Шәхескә кагылышлы УУГ: күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү, үз мөмкинлекләреңне бәяләү, үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру.

Планлаштырылган нәтиҗә: Татарча сөйләшә алу, сыйныфташларга һәм укытучыга карата игътибарлы булу, дәрестә кызыксынучан булу.

Материал: рус урта гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныфында укучы рус балалары өчен “Сәлам!” уку-укыту әсбабы.

Җиһазлау: уен өчен карточкалар, рәсемнәр, уенчыклар, интерактив такта, ноутбук, флеш-карталар, тавыш көчәйткеч.

Дәрес тибы: үткәннәрне ныгыту дәресе.

Методлар: уен технологиясе**,** өлешчә эзләнү, тикшеренү ысулы, җыр җырлау, акыл штурмы, парларда эш.

Эшчәнлек төрләре: аңлатмалы сөйләм, чагыштыру, әңгәмә үткәрү, дәреслек белән эш, уеннар уйнау, күрсәтмә әсбаплардан һәм техник чаралардан файдалану.

Чыганаклар: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыклары тарафыннан тәкъдим ителгән рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныфы өчен уку әсбабы (рус балалары өчен) Р.Ф. Бәхтиев, Казан: “Мәгариф — Вакыт” нәшрияты, 2018.

Бәхтиев Р.Ф., Гаппасова Р.Ч., Карпухина Н.И., Кашафетдинова Г.В., Маркова Э.М., Якупов Р.Н. “Сәлам!” 2нче сыйныф: рус телендә белем бирү оешмаларының татар телен өйрәнүче укучылары өчен эш дәфтәре. — Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017. — 160 б.

Бәхтиев Р.Ф., Гаппасова Р.Ч., Карпухина Н.И., Кашафетдинова Г.В., Маркова Э.М., Якупов Р.Н. “Сәлам!” 2 нче сыйныфю “Сәлам!” УМК сы белән эшләүчеләр өчен укытучы китабы. — Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017.

Дәрес барышы:

1. Оештыру. 1минут

Сыйныфта бер-береңә теләктәшлеккә, дустанә хезмәттәшлеккә корылган эш атмосферасы тудыру, төркемнәрнең дәрескә хәзерлеген күзәтү, барлау, белем алырга әзерлек алып бару. Укучыларда уңай психологик халәт тудыру.

— Исәнмесез, хәерле көн, укучылар! Барыгызга да яхшы кәеф телим.

— Исәнмесез.

— Әйдәгез, хәзер сәлам җырын җырлап алабыз.

Сәлам, сәлам! Хәерле иртә!

Сәлам, сәлам! Хәерле иртә!

Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!

Сау бул, дустым! Хәерле көн!

— Хәлләр ничек?

— Рәхмәт, шәп. (яхшы)

— Син кем ?

— Мин укучы малай, укучы кыз. (Исем)

— Сиңа ничә яшь?

— Миңа 8 яшь.

— Син кайда яшисең?

— Мин Казанда, шәһәрдә яшим.

2. Актуальләштерү. 4 минут

— Укучылар, татарча яхшы сөйләшәбез, әйеме!

— Әйдәгез, **“кайтаваз”(эхо)** уенын уйнап алабыз. Мин әйтәм, ә сез тыңлыйсыз, кабатлыйсыз. (Я говорю, вы повторяете.) Аңлашылдымы?

3. Уку мәсьәләсен кую. 2 минут

Укучылар, хәзер тактага карагыз әле. (Рәсемнәр тактага беркетелә.)

Сорауларга җавап бирү:

— Бу нәрсә? — Бу ... сарык, кәҗә, ат, сыер, бүре, аю, керпе, төлке, куян, эт, песи.

Кабатлау, тәрҗемә эше.

4. Белем һәм күнекмәләр ныгыту. 10 минут

“Серле капчык” уены. 1 укучы сумкадан уенчыкны сайлый, ләкин алмый.

— Бу нәрсә? дип сорый укучы. (Калганнар җавап бирә, сораулар да бирәләр.)

— Ул нинди? — Ул көрән, ак, кызгылт-сары, соры, куркак, хәйләкәр, зур, кечкенә.

— Ул нишли? — Сикерә, атлый, чаба, ашый, яши.

Берничә уенчык: песи, куян, төлке, аю.

5. Ял итү. 2 минут

“Зоопарк” уены. Бик тавышлы, ләкин күңелле уен. Укучыларга хайван исемнәре язылган битләр таратыла. Һәр хайван кимендә 2-3 булырга тиеш (парлар яки төркемнәр булырга тиеш). Укучылар бер-берсенең хайван атамаларын белми. Сигнал бирелгәч, укучылар парларын, төркемнәрен табарга тиеш булалар. Алар төркемдә ничә кеше икәнен белмиләр. Үз төркемен җыеп бетергәч, төркем кул күтәрә. Иң беренче җыелган төркем җиңүче була.

6. Өйрәнгән материалны ныгыту. 15 минут

Тактага ферма, урман рәсемнәре беркетелә. Балаларга битләр таратыла һәм укытучы аңлата.

— Укучылар, тактада йорт хайваннары, кыргый хайваннар да бар. Әйдәгез, аларны өйләренә урнаштырабыз, куябыз. Кем кайда яши? (Кто где живет?)

1 укучы тактага чыга (чиратлап), ә сез (калганнар) битләрдә эшләгез.

Җыр 35 нче бит.

Ла-ла-ла-ла-ла!
Эх, күңелле урманда!
Аю йөри лап-лап-лап,
Куян сикерә һап –һап!
Тиен чикләвек ашый,
Керпекәй гөмбә ташый.
Тик бүре генә улый-
Биек айга менә алмый.
У-у-у!
Ла-ла-ла-ла-ла!
Эх, күңелле авылда!
Эт өрә:
“һay-hay-hay-hay-hay**!”**
Песи әйтә:” Мияу-мияу!”
Сыер йөри болында,
Ат һәм сарык янында.
Тик кәҗә генә елый -
Ул бакчага керә алмый. Ми-ки-ки!

7. Эшчәнлеккә нәтиҗә ясау. Рефлексия (Презентация.) 4 минут

Укучылырның дәресне үзләштерү дәрәҗәсе ярдәмендә тикшерелә.

— Укучылар. Йорт һәм кыргый хайваннарын искә төшерик әле! Презентациядә рәсем чыга, аның турында сөйләү (төсе, файдасы, хәрәкәте). Укучылар бер-берсенең җавапларын тулыландыралар.

1 слайд. — Бу нәрсә? — Бу сарык. Ул безгә йон бирә.

— Бу нәрсә? — Бу төлке. Ул хәйләкәр, кызгылт-сары.

— Бу нәрсә? — Бу сыер. Ул безгә сөт, ит бирә.

— Бу нәрсә? — Бу тиен. Тиен чикләвек ашый.

2 слайд. — Бу нәрсә? — Бу куян. Куян сикерә. Ул соры, ак.

— Бу нәрсә? — Бу кәҗә. Ул сөт бирә. Кәҗә көрән.

— Бу нәрсә? — Бу бүре. Ул усал, соры.

— Бу нәрсә? — Бу керпе. Ул кечкенә. Гөмбә ташый, ашый.

— Бу нәрсә? — Бу ат. Ул күп эшли. Ат чаба, йөри, сикерә.

3 слайд. Авылда нәрсәләр яши? Җаваплар:

Дирижер уены. Мин әйтәм, сез кабатлыйсыз.

Сарык, кәҗә, ат, сыер.

4 слайд. Урманда нәрсәләр яши? Җаваплар: Тиен, бүре, куян, төлке.

— Укучылар, без бүген дәрескә нинди максат куйган идек? Дәрестә нәрсә өйрәндек?

— Максатка ирештекме? Укучылар максатка ирешү-ирешмәү турында әйтәләр:

Бүгенге дәрестә мин:

— …өйрәндем

— миңа…кызык булды

— миңа…авыр булды

— мин ... аңладым.

1. Смайликлар белән дәресне бәяләтү. Укучылар дәресне бәяләү өчен смайликлар сайлап алалар. (Дәрес бик ошады, дәрес ошады, дәрес ошамады.)

Таблицага үзбилге кую.

8. Өй эше бирү. (Өч дәрәҗәдә бирелә**) 2 минут**

А) Таратылган биттә йорт хайванын ясарга.

Б) Таратылган биттә йорт хайваны турында язарга.

В) Рәсемне күрсәтеп йорт хайваны турында сөйләргә.

Йомгаклау.

— Минемчә, куелган максатыбызга ирештек. Укучылар, сез бик әйбәт эшләдегез. Әфәрин! Дәресебез шуның белән тәмам. Сау булыгыз! Уңышлар сезгә!

Һадиева Резеда Мәҗит кызы,
Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы муниципаль
белем бирү учреждениясе
“Лекарево урта гомуми белем бирү мәктәбе”
туган тел һәм әдәбияты укытучысы

2 нче сыйныфның рус төркемнәрендә “Шәхси гигиена предметлары” темасы буенча татар теле дәресе

Максат. Дидактик максат. 1. “Шәхси гигиена” темасына караган сүзләрне һәм җөмлә калыпларын сөйләмдә кулланууны оештыру.

2. Тартымлы исемнәрне дөрес әйтергә күнектерү; диалогик сөйләм оештыру; алган күнекмәләрне активлаштыру.

3. Шәхси гигиена предметларының нинди икәнен, аларны кулланып, нәрсә эшләгәнеңне әйтә, сорый белергә өйрәтү.

Үстереш максаты. 1. Кирәкле мәгълүматны сайлап алырга өйрәтү. 2. Үз фикереңне дәлилли белергә өйрәтү. 3. Ишетеп аңлау күнегүләре аша игътибарлылыкны үстерү.

Тәрбияви максат: укучыларда чисталык, пөхтәлек кебек сыйфатлар тәрбияләү.

Дәреснең тибы: Лексик грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресе.

Җиһазлау: уен өчен карточкалар, билгеләү өчен таблицалар, мультимедиа, презентация.

Дәрес барышы:

I. Оештыру.

1. — Исәнмесез, укучылар!

— *Исәнмесез!*

— Хәерле көннәр сезгә!

— *Хәерле көн!*

— Кәефләрегез ничек?

— Шәп!

— Мин үзем генә килмәдем, сезгә керпе дә килде. Әйдәгез, аның белән дә исәнләшик.

— Исәнме, керпе!

— Исәнмесез!

— Хәлләр ничек?

— Начар.

— Ребята, наш ежик грязный, что бы помощь ежу, мы должны делать разные упражнения. Сез ризамы?

— Әйе, риза.

II Аудирование.

— У вас на столах есть лист оценивания. После каждой проделанной работы вы оцениваете себя и приклеиваете напротив задания смайлик с определенным настроением. Улыбается, и показывает большой указательный палец, если у вас все получилось, улыбка, если все получилось, но были затруднения, улыбки нет, если вам нужна была помощь.

III. Төп өлеш.

1. На столах есть конверты с играми. Раскладываем пазлы и собираем, должна получиться ассоциация к одной теме. Что за ассоциация получилось у вас? Для чего нужны эти предметы? О чем мы с вами будем разговаривать?

— Личная гигиена. О чистоте, чтобы были чистыми.

— Личная гигиена — шәхси гигиена. Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №1.

— Чиста булыр өчен нинди предметлар кирәк?

— Мыло, полотенце, расческа, зубная паста.

— Мыло — татарча ничек була?

— Сабын.

— Сөлге.

— Тарак.

— Теш щеткасы.

Предмет рәсемнәре тактага беркетелә.

2. — Керпе сезгә капчык бирә, шул капчыкны капшыйсыз һәм нәрсә икәнен әйтәсез.

— Сабын, тарак, сөлге, теш щеткасы.

— У вас на столах листы бумаги, один из вас пишет на листе предмет, который у вас на руках, передает лист следующему, который добавляет свое слово и т.д. Слова не должны повторяться. На эту работу вам отводится 1 минута. (РАУНД ТЭЙБЛ структурасын куллану.) Сабын — яшел, матур, тәмле, чиста. Башта берегез укый, аннары икенчегез.

— Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №2.

3. — Предметларны алышынабыз, ләкин татарча сорыйбыз.

— Миңа сабын бир әле.

— Мә

— Рәхмәт.

Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №3.

4. — Сезгә керпе сораулар бирә, Әйе, юк, дип җавап бирегез.

— Бу таракмы?

— Әйе, бу тарак.

— Юк, бу тарак түгел.

Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №4.

5. “Нәрсә юк?” уены. Тактага предмет рәсемнәре эленгән, мин бер предметны алып куям, сез нәрсә юклыгын әйтәсез.

Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №5.

6. Минем кушымчаларын слайд ярдәмендә искә төшерү.

“Дөрес әйт” уенын уйнау.

Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №5.

7. Синең кушымчаларын слайд ярдәмендә искә төшерү.

“Дөрес әйт” уенын уйнау.

Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №5.

8. Өстәлдә конвертлар (№8) бар. Ситуатив күнегүләрне эшләү.

А) попроси у мамы мыло;

Б) спроси у друга, есть ли у него зубная щетка;

А) попроси себе красное полотенце;

Б) попроси у папы расческу;

А) спроси у друга, есть ли у него мыло;

Б) попроси себе зеленое полотенце.

Җавапларын чиратлашып укыйлар.

— Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания № 8.

9. Дополни диалог и разыграй его.

А) — Синең сабының бармы?

— Әйе, бар.

— Ул кайда?

— Ваннада.

Б) — Синең сөлгең нинди?

— Яшел.

— Ул кайда?

— Ваннада.

В) — Синең тарагың бармы?

— Бар.

— Ул кайда?

— Сумкада.

— Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №9.

IV. Ял минуты.

— Әйдәгез, уйныйбыз...

— Әйдә.

— Мунчала, сабын кулда.

Тәнне юамын суда.

Юа, юа юылган,

Сабын суда юк булган.

V. Төп өлеш.

— Рәсемнәргә карап НИШЛИ? дигән сорауга җавап бирәбез. Рәсемнәр аша

Бит юа — моет лицо

Кул сөртә — вытирает руки

Чәч тарый — расчесывает волосы

Теш чистарта — чистит зубы

10. “Ул нишли?” уенын уйныйбыз. Один ученик выходит и показывает движениями: моет руки, вытирает лицо, чистит зубы, расчесывает волосы и т.д. А остальные отгадывают.

Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №10.

11. Нәрсә белән? җөмләләрне тоташтыр

Мин сабын белән теш чистартам.

Мин сөлге белән бит юам.

Мин тарак белән кул сөртәм.

Мин теш щеткасы белән чәч тарыйм.

Карточкаларны командалар алышынып тикшерә

Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №11.

12. — Мы узнали новые слова, а теперь будем учиться употреблять их в своей речи.

— Данил, син сабын (сөлге, тарак) белән нишлисең ?

(Мин сабын белән кул юам. Мин тарак белән чәч тарыйм. Мин теш щеткасы белән теш чистартам. Мин сөлге белән бит сөртәм.)

— Ә сезнең шәхси гигиена әйберләре бармы? *(Әйе)*

а) I, II зат тартым кушымчалары белән эш:

- *минем сабыным;*
- *минем сабыным зәңгәр;*
- *минем сабыным бар.*

ә) Диалог (төркемнәрдә сөйләшү):

— Алена, синең сөлгең бармы?

— Әйе, бар.

— Ул нинди?

— Ул йомшак.

Оцените себя и приклейте смайлик напротив задания №12.

XII. “Юындыр” мультфильмыннан өзек карау.

— Укучылар, димәк, безгә ни өчен сабын, сөлге, тарак кирәк?

(*Чиста, пөхтә булыр өчен)*

— Ә ни өчен чиста, пөхтә булырга кирәк?

(Укучылар үз фикерләрен әйтәләр)

— Балалар, карагыз әле безнең керпе нинди булган? Чиста, йомшак. Ул шатлана. Без аңа ярдәм иттекме?

— Әйе.

— Лист самооценки проверяем, кто у нас отлично получил?

— Сезнең дәрес ахырында кәефләрегез кайсы рәсемгә туры килә?

— Чиста малай, елмаеп тора торган. (Беренче рәсемне сайлаганнар, гел чиста, пөхтә йөрүчеләр.)

— Пычрак малай, елап тора торган. (Икенче рәсемне сайлаучылар бик аңламадылар, ләкин аңларга теләк бар.)

— Иңсәләрен селкетеп торган малай. (Аларга яңа сүзләрне яңадан өйрәнергә туры киләчәк).

XI. Йомгаклау. Рефлексия.

— Укучылар, безнең тема нинди иде?

— Шәхси гигиена предметлары

— Без нинди яңа сүзләр белдек?

— Сабын, сөлге, тарак, теш щёткасы. Кул юа, бит сөртә, теш чистарта, чәч тарый.

— Нинди җөмләләр төзедек?

— Мин сабын белән кул юам. Мин сөлге белән бит сөртәм. Мин тарак белән чәч тарыйм. Мин теш щёткасы белән теш чистартам.

XIII. Өй эше.

— Ә хәзер көндәлекләрне ачыгыз. Өй эше язабыз. 1 нче өй эше: яңа сүзләрне кабатларга. 2 нче өй эше: карточкаларда эш. Җөмләләрне язып бетерергә.

Мин сабын белән .....

Мин теш щёткасы белән ....

Мин сөлге белән .....

Мин тарак белән ....

3 нче өй эше: шәхси гигиена предметлары белән җөмләләр төзергә.

Керпе сезгә РӘХМӘТ әйтә, кечкенә бүләкләр тапшыра. Чиста, матур, пөхтә булып йөрегез. Уңышлар сезгә! Дәрес өчен барыгызга рәхмәт.

Низамиева Гөлназ Радик кызы,
Казан шәһәре Совет районы
156 нчы гомуми урта белем мәктәбенең
туган тел һәм әдәбияты укытучысы

4 нче сыйныфның рус төркемнәрендә “Кая?”, “Кайда?”, “Кайдан?” сорауларын ныгыту, кабатлау буенча татар теле дәресе

Максатлар: Кая? Кайдан? Кайда? сорауларын актив сөйләмдә дөрес куллану, кушымчаларны дөрес аңлап куллану өстендә эшләү, кабатлау, тема буенча белемнәрне ныгыту; диалогик һәм монологик сөйләм телен үстерү.

Көтелгән нәтиҗәләр:

Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: бер-береңә игътибарлылык, дуслык хисләре барлыкка килү.

Метапредмет нәтиҗәләре:

Регулятив УУГ: эшчәнлекне планлаштыра, үз алдыңа максат куя белү, нәтиҗә ясау; кыенлыклардан чыгу юлларын эзләү; үз мөмкинлекләреңне бәяләү.

Танып-белү УУГ: дәрестә ориентлаша белү, төрле биремнәр үтәү, проблема кую һәм аны чишү.

Коммуникатив УУГ: үз фикереңне җиткерә, башкаларны тыңлый белү; диалогта, әңгәмәдә катнашу осталыгын үстерү.

Предмет нәтиҗәсе: «Кая? Кайдан? Кайда? сораулары» темасын кабатлау; сөйләм теле, фикерләү сәләте үсү.

Дәрес тибы: белем һәм күнекмәләрне ныгыту.

Эш формалары: фронталь, индивидуаль, парлап эшләү.

Җиһазлау: презентация, бирем карточкалары, үзбәяләү карточкалары, ноутбук, тавышкөчәйткеч, интерактив такта.

Дәреслек: Р.З. Хәйдәрова, Н.Г. Галиева, Г.М. Әхмәтҗәнова Күңелле татар теле. Рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 4 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус балалары өчен). Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2017.

Дәрес барышы:

I. Оештыру.

— Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн!


— Хәерле көн миңа!

Хәерле көн сиңа!

Хәерле көн сезгә!

Хәерле көн безгә!

— Дәресебезне башлап җибәрү өчен, әйдәгез, фонетик зарядка ясап китик. Без авазларны таудан шудырабыз. Иң беренче [а] авазыннан башлыйбыз. ([ә], [ү], [ө])



— Яхшы, менә сез инде тулысынча дәресебезне башларга әзер.

II. Белемнәрне актуальләштерү.

— Балалар, искә төшерегез әле, без үткән дәрестә нәрсәләр турында сөйләшкән идек?

(Бездә кошлый торган һәм бездә кошламый торган кошлар турында)

— Әйе, шулай. Менә мин аларның кайберләрен сезгә күрсәтеп китим әле. Әйтегез, кайсысы нинди кош һәм кайсысы бездә кала икән боларның?

(Экранда төрле кош сурәтләре, укучылар аларның атамаларын әйтәләр. Бездә кышлый торган кошлар экранда кала, ә җылы якка китә торганнары юкка чыгып бара. Балалар чиратлап җавап бирәләр. Мәсәлән: кыр үрдәге бездән китә, ул җылы якка китә. Ала карга бездә кала).



III. Яңа тема үзләштерү.

1) — Балалар, хәзер игътибар белән тагын тактага карагыз. Мин сезгә җөмләләр күрсәтәм. Сез дөрес итеп укырга тырышыгыз һәм билгеләнгән сүзләргә сорау куярсыз.

А) Аккош ерак <u>күлдә</u> яши. (Кайда?)

Б) Торналар <u>җылы якка</u> киттеләр. (Кая?)

В) Песнәкләр <u>урманнан</u> шәһәргә кайттылар. (Кайдан?)

— Бу күнегүдә безнең нинди сораулар килеп чыкты?

(Кая? Кайда? Кайдан?)

— Рәхмәт, укучылар.

2) <u>Уен “Артык сүзне тап, иясенә ат”.</u>

— Алга таба без уйнаячак уенны игътибар белән тыңлагыз. Уеныбыз “Артык сүзне тап, иясенә ат” дип атала. Сез бирелгән сүзләрдән арасыннан артык сүзне табасыз, сорау куясыз һәм ул сүзне кемгә дә булса “ыргытасыз”. Ул кеше аның белән җөмлә төзиячәк. Киттек!

эшкә — Кая? агачта акчарлактан

аюга вокзалда — Кайда? бакчадан — Кайдан?

керпегә яфракта саесканнан

пошига үләндә каргадан

— Молодцы, балалар, булдырдыгыз! Ә хәзер әйтегез әле, бу күнегүләрдә без нинди сораулар куйдык? Нинди сорауларга җавап бирдек?

(Кая? Кайда? Кайдан сорауларын куйдык.)

— Әйе, бик дөрес, бу күнегүдә дә безнең шул ук сораулар килеп чыкты. Ничек уйлыйсыз, безнең бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр икән?

(Кая? Кайда? Кайдан ? сорауларны кабатлау.)

— Әйдәгез, кагыйдәсен дә искә төшереп китик. Бу сорауларның нинди кушымчалары бар икән?

Кая? — Куда? — га/-гә, -ка/-кә

Кайда? — Где? — да/-дә, -та/-тә

Кайдан?— Откуда? –дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән

(Кагыйдәләр һәм бу сорауларга хас булган кушымчалар искә төшерелә.)

Физминутка.

— Укучылар, әйдәгез, ял итеп китик.

Бер ике, без бастык,

Чап-чап итеп кул чаптык,

Аякларны бер урында

Тып-тып иттереп бастык.
Бер утырдык, бер бастык,
Инде хәл дә без алдык,
Тыныч кына утырдык.

IV. Ныгыту.

1) — Хәзер сез алдыгызда булган карточкаларны аласыз. Монда текст бирелгән, әмма кушымчалары төшеп калган. Сез шул урыннарга тиешле кушымчаларны куеп язасыз.

Карточка:

Көз
Көз җитте. Көннәр салкын, урам... яңгыр ява. Агачлар... сары яфраклар кола. Урман... җәнлекләр йокыга әзерләнәләр. Сандугач, кыр казы, торна, карлыгач җылы як... китәләр. Әмма песнәк, кызыл түш, ала карга һәм чыпчык бездә кала. Төньяк... салкын җилләр исә. Алар кар болытларын безгә алып киләләр.

(Балалар карточкаларда эшлиләр.)

— Эшләп бетерсәгез, партадашыгыз белән алышынасыз һәм тактадагы үрнәк белән тикшерәсез. Билге куясыз: бер хатасы да юк — “5”, бер яки ике хатасы булса — “4”, өч хатасы булса — “3” куясыз.

— Я, балалар, кемнең “5” — ? “4” — ? “3” — ?

(Балалар үзләренең билгеләрен әйтеп чыгалар.)

— Хәзер бу текстны тәрҗемә итәрбез.

(Укучылар текстны тәрҗемә итәләр.)

2) Уен “Дуэль”.

— Уйнап алабызмы, укучылар? Алдагы уеныбыз “Дуэль” дип атала. “Дуэль” булгач, без ярышачакбыз, димәк (соревноваться будем). Миңа ике укчы кирәк булачак. Сезгә сүзләр язылган карточкалар бирәчәкмен, аларны идәнгә куелган “Кая? Кайда? Кайдан?” сораулары буенча үзгәртеп, кушымчалар ялгый-ялгый алга барасыз. Һәр дөрес җавап саен бер адым алга атлыйсыз. Кем сорауларга җавап биреп уртага килеп җитә, шул җиңүче. Ялгышкан укучы алга таба адым ясый алмый. Калганнар кем ялгышмыйча сүзләрне әйтә, шуны игътибар белән карап, тыңлап бара. Җиңүчене билгелисез.

(Мәсәлән: авыл-авылга-авылда-авылдан)

(Барлыгы 3 пар чыгып уйнап алалар.)

V. Рефлексия.

— Әйдәгез, дәрескә нәтиҗә ясыйк.

— Мин дәрестә бүген нәрсә эшләдем?

(Укыдым, яздым, кабатладым, уйнадым, сөйләдем.)

— Мин дәрестә нәрсә эшләмәдем?

(Йокламадым, җырламадым, йөгермәдем.)

— Сезнең алдыгызда кечкенә генә йолдызчыклар ята, балалар. Әгәр сезгә дәрес ошаса, барысын да аңласагыз **!** билгесе куясыз.

— Әгәр ниндидер сорауларыгыз калса **?** билгесе куясыз.

VI. Өй эше.

— Өй эшен сез шушы йолдызчыкларга карап аласыз. Кемнең **!** билгесе 1 нче номерлы эш, ? билгесе куйган укучылар 2 нче өй эшен эшли.

1. Берәр кош турында мәгълүмат (информация) язып килергә.
2. Кайда? Кая? Кайдан? сораулары ярдәмендә 3 җөмлә төзеп килергә.

— Дәрес тәмам, чыгарга мөмкин. Сау булыгыз, укучылар!

Әбсәләмова Ильмира Хәмит кызы,
Казан шәһәре Вахитов районы
39 нчы мәктәпнең татар теле һәм
әдәбияты укытучысы
Җиһангирова Миләүшә Васыйл кызы,
Казан шәһәре Вахитов һәм
Идел буе районнарының
укыту-методик бүлек методисты

4 нче сыйныфның рус төркемнәрендә «Минем дусларым. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше» темасы буенча татар теле дәресе

Максатлар:

1. Дидактик: исемнәрнең тартым белән төрләнеше бүлеге буенча үткәннәрне искә төшерү, тема буенча сөйли белү күнекмәләрен камилләштерү.
2. Үстерешле: логик һәм образлы фикер эшчәнлеге үсеше өчен җирлек тудыру.
3. Тәрбияви: аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү һәм үз эшчәнлекләренә адекват бәя күнекмәләре үсеше өчен җирлек тудыру.

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

1. Шәхес буларак үсешне күрсәтүче нәтиҗәләр.

Үз эшчәнлегенә адекват бәя бирү һәм үз мәнфәгатьләре белән сыйныфташлары мәнфәгатен килештерә белү күнекмәсе камилләшү.

2. Метапредмет нәтиҗәсе:

- т**анып белү гамәлләре:** терәк сүзләр (исемнәр), тәкъдим ителгән формула ярдәмендә сөйләмгә чыгу, моделләштерү, модельне укый, куллана белү күнекмәләре камилләшү;
- **коммуникатив гамәлләр:** тыңлый, ишетә, үз фикерен татар телендә дәлилле белдерү күнекмәсе камилләшү;
- **регулятив гамәлләр:** укытучы ярдәме белән дәрескә максат кую һәм эшне планлаштыруда катнашу; үзләштерелгән белемнәрне кулланып, эшчәнлектә катнашу; үзконтроль, үзбәя күнекмәләре камилләшү.

3. Предмет буенча нәтиҗә — дуслык мөнәсәбәтләрен, геометрик фигураларны (квадрат, түгәрәк, ромб, өчпочмак), төсләрне (зәңгәр, сары, кызыл, яшел) белдерүче лексиканың активлашуы, исемнәрнең тартым белән төрләнеше үзенчәлеге актуальләшүе (уку, язу, диалогик һәм монологик сөйләмдә актив кулланылышка кертү). Исемнәрнең тартым белән төрләнеш үзенчәлекләрен, дуслык мөнәсәбәтләрен белдерүче лексика белән беренчел кулланылышка кертү.

Дәреснең тибы: диалогик-монологик сөйләм дәресе. Сөйләм формуласын чыгару.

Ресурслар:

- 4 нче сыйныф өчен дәреслек .2 нче кисәк. Р.З. Хәйдарова, Г.М. Әхмәтҗанова — 4 нче б.,
- техник чаралар: ноутбук, презентатор, интерактив такта.
- күрсәтмә материал (презентация);
- карточкалар
- тарату материаллары

— исемнәрнең тартым белән төрләнешен кертү өчен терәк схемалар;

— ассоциатив фикер эшчәнлеге өчен интеллект карта моделе;

— кәеф төсмәрләрен чагылдырган рәсемнәр (кар бабай рәсемнәре);

— геометрик фигураларны (квадрат, түгәрәк, ромб, өчпочмак)

— акросүз моделе.

Дәрес барышы

I. Оештыру этабы.



Исәнмесез, укучылар!

Хәерле иртә! Барыгызга сәламәтлек телим!

Күк йөзендә ак чәчәктәй

Кояш нур сибә,

Сезнең елмаюлы йөзләр миңа дәрт бирә.

Дәресебезне башлыйбыз.

Сезнең кәефләрегез ничек? Сезнең алдыгызда кар бабайлар ята. Сезнең кәефегезгә нинди кар бабай туры килә. Миңа күрсәтеп алыгыз әле. Мин дә сезне күрүгә бик шат. Дәресебез дә шулай күңелле үтәр дип ышанып калам.

II. Актуальләштерү.

Укучылар, әйдәгез уен уйнап алабыз!

1) Кем тизрәк таба уены.

Тактада хәрефләр. Бу хәрефләрдән нинди сүз ясап була? (Дуслык)

Әйе, дуслык. Ә дуслык ничек тәрҗемә ителә? (Дружба)

Дуслык нәрсә ул? (булышу, аралашу)



Сез дуслыкны ничек аңлыйсыз? (Как вы понимаете слово дружба?)

Сезнең дусларыгыз бармы?

2) Сүзлек белән эш.

Дус сүзенең сүзлектәге аңлатмасы болай: дуслык-фикерләрнең, карашларның уртаклыгына, үзара рухи якынлыкка һәм ышануга нигезләнгән мөнәсәбәт. (Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге)

(Дружба-это близкие отношения, основанные на взаимном доверии, привязанности, общности интересов. (С.И.Ожегов Словарь русского языка)


Без бүген нәрсә турында сөйләшәбез? (дуслык турында)

— Әйе, дөрес,без бүгенге дәрестә: “Дуслык”турында сөйләшәбез.

Игътибар тактага.

— Укучылар, һәр кешенең дусты була. Минем дустым — Гөлназ. Игътибар тактага: (слайдта рәсемнәр)

3) Соруларга җавап бирү:



— Чип белән Дейл дуслармы?

— Малайның дусты бармы?Ул нәрсә?

— Бу рәсемдә нәрсәләрне күрәсез? Бу песиләр дусмы?

— Бала белән күбәләк дуслармы?

— Бу рәсемдә кемнәр дуслар?

— Этнең дусты кем?

Игътибар белән видеоны карап үтәбез.

— Бу видео ошадымы? Алар чын дуслармы? Маймыл белән эт чын дуслар.

Бүген дәресебезнең темасы ничек була? “Минем дустым”.

Чын дустың булу — ул зур бәхет!



III. Уку мәсьәләсен кую.

1) Ребус чишү.

— Әйдәгез ребус чишеп алыйк. Нинди сүз килеп чыга? (алмашлык— местоимение)

2) Модельләштерү.

— Укучылар, хәзер сезнең белән алмашлыкның моделен бергәләп төзеп алый эле. Модельнең беренче өлешен төзер өчен игътибар белән җырны тыңлыйк.

— Укучылар, Җырда нинди зат алмашлыкларын ишеттегез? (Мин, син, ул, без, сез, алар)

Алар нинди сорауга җавап бирә?(кем?)



Модель № 1


— Укучылар, бу зат алмашлыклары.

IV. Уку мәсьәләсен (УМ) адымлап чишү.

1) Контроль кисем.

— Балалар, ә хәзер Нетбукларда тест эшләп алабыз. Җөмләләрдә зат алмашлыкларын куярга кирәк. Җавапның дөрес вариантын күрсәтегез.

1. (Сез) Һәрвакыт дус яшисез.
2. Дәрестән соң , (Мин) чанада шуам.
3. Кыш көне (Без) бергә урамда уйныйбыз.
4. (Алар) бик яхшы дуслар.
5. Ә (Син) бүген тауга барасыңмы?.
6. Әлбәттә, (Ул) чаңгыда яхшы шуа.



— Әйдәгез, бергәләп тикшерәбез. (Бала дөрес җөмләне әйтә, алмашлыклар чыгып бара)

Әйдәгез эшне бәялибез. Үз эшегезне кар бабайлар белән бәяләгез! 6 балл алган балалар — бу кар бабайны күрсәтегез, 5 балл алган балалар — бу кар бабайны күрсәтегез. 4 балл алган балаларга — тырышырга кирәк.

Игътибар тактага.

— Укучылар, Һәр кешенең дусты була. Минем дустым — Гөлназ.

— Ә синең дустың бармы? Ул кем? (Аның исеме ничек?)

— Хәзер барыбыз бергә тагын бер тапкыр кабатлыйк:

Минем дустым. Синең дустың. Аның дусты.

— Ә хәзер алмашлыкларны күплек санда кабатлыйк.

Безнең дустыбыз. Сезнең дустыгыз. Аларның дуслары.

Менә без сезнең белән модельнең икенче өлешен таптык.

— Укучылар, Бу алмашлыклар нинди сорауга җавап бирәләр? (Кемнең?)

— Әйе, дөрес. Бу — тартым алмашлыклары.Это притяжательные местоимения.



2) Модельләштерү.

Модель №2

— Сез бу модельдә тартым алмашлыкларын кушымчалар белән күрәсез. Сез алар белән таныш. Әйдәгез укучылар бу алмашлыклар ярдәмендә сүзтезмәләр төзик.

— Укучылар, тактага карагыз әле. Бу шартлы билгеләр. Условные знаки.

Сезнең алдыгызда да шундый ук шартлы билгеләр ята.

— Бу зәңгәр шакмак.

— Сез дә Миңа зәңгәр шакмакны күрсәтегез әле.



Зәңгәр шакмак тартым алмашлыкларын белдерә. Кемнең? Соравына җавап бирә. Әйтегез әле, бу нинди алмашлыклар? (Минем, синең, аның, безнең, сезнең, аларның).

— Хәзер кызыл ромбны күрсәтегез.

Кызыл ромб Кем? Нәрсә? соравына җавап бирүче сүзне белдерә.

— Әйдәгез бу фигуралар ярдәмендә сүзтезмә төзик.

Минем әнием, синең апаң, безнең йортыбыз....

V. Ныгыту.

1) Интеллект карта белән эш.

— Укучылар, Сезнең алдыгызда шундый карта ята. Картада сүзләр язылган. Синең дустың нинди? Шул сорауга туры килгән 5 сүзне түгәрәккә

сайлап языгыз. Эшне парлап башкарасыз. Риза булсагыз болай күрсәтәсез. Риза булмасагыз шулай күрсәтәсез. Эшне башкаруга сезгә 2 минут. Балалар әйдәгез укыгыз.

— Укучылар, бу сүзләр нинди сорауга җавап бирәләр? (Нинди?)

— Әйе, дөрес. Хәзер сары түгәрәкләрне күрсәтегез.



Сары түгәрәк нинди соравына җавап бирүче сүзне белдерә.

Сайлаган сүзләрне кулланып, фигуралар ярдәмендә җөмлә төзик.

Минем дустым акыллы. Синең дустың ярдәмчел.

2) Физкультминутка

Хәзер басып, ял итеп алабыз.

Менә сиңа уң кулым,

Менә сиңа сул кулым,

Син бит минем якын дустым

Менә сиңа куш кулым.

3) Акросүз төзү.

Әйдәгез әле, бергәләп акросүз төзеп карыйк.

Нәрсә соң ул акросүз? Кем белә?

Бу хәрефләргә бергәләп матур сүзләр эзлик. Дуслар нинди була икән. Сүзлектән карап матур сүзләр табыйк. Сүзлек сезнең алдыгызда.



Д — дәртле, дәһи, данлы

У — уңган, уйчан, уңышлы

С — сабыр, сөйкемле, сизгер, сәләтле

Т— тәртипле, тырыш, тыйнак

Ы — ышанычлы

М — мәрхәмәтле

Никадәр яңа, матур сүзләр белдек.

4) Диалог төзү.

— Ә хәзер укучылар дәреслек белән эшлик. 5 бит, 5 күнегунең а өлешен эшлибез. Диалогларга төшеп калган репликаларны өстә, дустың белән сөйләш.



— Әйдәгез, тикшерәбез.

— Эшебезне дәвам итәбез. Хәзер яшел өчпочмакны күрсәтегез.

Яшел өчпочмак нишли, нишләде соравына җавап

бирүче сүзне белдерә, мәсәлән: яза, бии, укый, эшли, җырлый, укыды, язды, укыды...

5) Җөмләләр төзү.

— Ә хәзер бу фигуралар ярдәмендә җөмлә төзик.

Минем дустым яхшы укый.

— Сез дә фигуралар кулланып җөмлә төзегез.

Синең дустың матур сөйли. Безнең дусларыбыз күңелле уйныйлар...

— Укучылар, без сезнең белән җөмләнең формуласын таптык. Аның ярдәмендә төрле матур җөмләләр төзеп була.

6) Табышмак. Йорт төзү.



Мин сезгә табышмак әйтәм. Тыңлагыз!

Бу матур һәм зур бина,

Тәрәзәләре якты.

Түбәләре ямь-яшел,

Эчендә гаилә яши. (Йорт)

— Укучылар, бу формуланы кулланып фигуралар белән бергәләп йорт төзибез. Миңа игътибар белән карагыз!



Менә матур йорт килеп чыкты.

Әзер булды йортыбыз

Якын дусларым килде.

Тәмле чәйләр эчәбез

Татарча сөйләшәбез

Бергә күңелле булды

Йорт шатлык белән тулды!

— Укучылар, карагыз әле, без сезнең белән Дуслык йортын төзедек.

Казаныбызда да Дуслык йорты бар. Бу йортка төрле милләт кешеләре кунакка килә. Алар анда җырлыйлар, биилəр, аралашалар.

7) Монологик сөйләм төзү.



Сезнең дусларыгыз кайда яши? Менә минем дустым Япониядә яши.


— Ә синен дустың кайда яши? (Минем дустым Казанда яши)

— Укучылар, бүген ничәнче число? (23 нче гыйнвар)

— Бүген кулдан хат язу көне (День ручного письма)

Файлларда төрле төстәге куллар ята. Кул ул исәнләшү, дуслашу билгесе. Шушы кулларга безнең бүгенге формулаларны кулланып дусларыгыз турында языгыз. Формулалар экранда бирелгән.

8) Хат язу.



1. Минем дустым
2. Минем дустым акыллы
3. Минем дустым яхшы укый.
4. Сезнең бик яхшы дусларыгыз бар икән.

V. Рефлексия.

Хатларны хат ташучы күгәрченгә тапшырыйк.

— Укучылыр, карагыз әле. Нинди матур күгәрчен барлыкка килде. Күгәрчен ул тынычлык кошы. Хат ташучы кош. Җылы сүзләр язган хатыбыз дусларыбызга барып җитсен! (конвертны күгәрченгә тапшырабыз)

Дуслык хисе дөньябызны җылытсын, төрле милләтләр дус яшәсен. Җир йөзендә тынычлык булсын. (Бергәләп җырлыйбыз)



Дуслар белән яшәү ямьле!
Дуслар белән күңелле!
Дуслар белән аралашу
Озынайта гомерне!
Дусларыма рәхмәт әйтеп,
Ярсып тибә йөрәкләр.
Бетмәс шатлык, сүнмәс сөю
Миннән сезгә теләкләр!

Дәрес тәмам. Укучылар, сезгә дәрес өчен зур рәхмәт. Чыгарга мөмкин. Сау булыгыз!

Файдаланган әдәбият

1. Лотарева, Т.В. Методика обучению английской речи во II классе школы с преподаванием ряда предметов на английском языке: автореф. дис. … канд. пед. наук / Т.В. Лотарев. — М., 1973. — 8 с.

2. Жирар, Д. Диалог: за и против / Д. Жирар // Методика преподавания иностранных языков за рубежом. — 1976. — Вып. 2. Т.2. — С. 422–433.

3. Роовет, Э.Й. Обучение речевому общению / Э.Й. Роовет // Общая методика обучения иностранным языкам: Хрестоматия. М., 1991. — С. 223.

4. Маргулис, В.Д. Вербальный текс как единица обучения (интегративная методика преподавания естественных языков) / В.Д. Маргулис. — Челябинск, 1990. — С.88.

5. Активные методы обучения в высшей школе: учебно-методические материалы по программе повышения квалификации «Современные педагогические и информационные технологии» / под ред. Е.Ю. Грудзинской и ВВ. Марико. — Нижний Новгород, Изд-во ННГУ им. Н.И. Лобачевского, 2009.